# ДИН вә Мәгыйшәт

6+

*Ий мөэминнәр! Барчаларыгыз да берләшкән хәлегездә Аллаһ арканына, ягъни Аның диненә ныклап ябышыгыз! Һәм һич тә аерылмагыз һәм бер-берегездән киселеп, төрле юлларга китмәгез!*
*(Корьән, 3:103)*

Газетада Аллаһы Тәгаләнең исемнәре, Корьәннән аятьләр бар, тиешсез урынга куллануудан саклаyыгыз!

№7 (240) РАМАЗАН – ШӘҮВӘЛ – 1436 ТАТАРСТАН МӨСЕЛМАННАРЫ ДИНИЯ НӘЗАРӘТЕ БАСМАСЫ



реклама

AZAN ИСЛАМ АВАЗЫ ИНТЕРНЕТ-РАДИОСЫ

www.radioazan.ru


# Татарстан Республикасы мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның Ураза гаете уңаеннан котлавы

**Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахиим! Мөхтәрәм дин кардәшләребез! Татарстан мөселманнары Догния нәзарәте һәм шәхсән үз исемемнән ихластан барыгызны да Ураза гаете белән котлыйм!**

Ураза гаете исламда иң мөбарәк бәйрәмнәрнең берсе һәм ул толерантлык, кардәшлек, мәрхәмәтлелек билгесе. Ураза бәйрәме исламның тынычлык һәм үсеш дине булуына бер дәлил.

Быел рамазан җәйнең иң кызу июнь-июль айларына туры килде, төннәр дә бик кыска булды. Әмма бернинди авырлыкларга карамастан, без бары Раббыбыз мәрхәмәтенә өмет итеп, эчке бер шатлык һәм җиңеллек белән уразалар тоттык, Аллаһка шөкер. Пәйгамбәребез (аңа Аллаһның рәхмәте һәм сәламе булсын!) ураза тотуның күркәмлеге турында аңлатып, бер хәдисендә әйтә: “Ураза тотучының ике шатлыгы булыр: ифтар шатлыгы һәм Аллаһы Тәгалә белән очрашу шатлыгы”. Барча мөселманнар мөбарәк рамазан аенда тәравих намазларында Раббыбызга сыендылар һәм илебезгә, якыннарыбызга бәрәкәтле көннәр теләделәр.

Бүген мөселманнарның зур бәйрәме, һәркайсыбыз аны дулкынлану белән каршы ала. Чөнки Ураза бәйрәме якынлашканда күңелләребезгә ике хис тула. Беренчесе аның – шатлык, Аллаһ ризалыгы өчен ураза тотуыбызга сөенеч. Икенчесе моңсулык, догаларыбыз кабул була торган күркәм айдан аерылу сагышы.

Мөхтәрәм җәмәгать! Рамазан ае теләгән һәркемгә дин юлына басарга, рухи яктан үсәргә мөмкинлек бирде. Күпләр бу айда ярамас гадәтләрдән арындылар, телләрен яман сүзләрдән тыйдылар, вакытларын күбрәк гаиләләренә багышладылар һәм төннәрен өстәмә гыйбадәтләрдә уздырдылар, догалар кылдылар. Алга таба бәйрәм көннәрен тормыш мәшәкатьләре, гадәти көннәр алыштырыр. Менә шул гадәти көннәрдә дә рамазанда кылган матур гамәлләребезне дәвам итсәк, күңелләребезне начар уйлардан сакласак иде!

Аллаһы Сөбхәәнәһү вә Тәгалә тоткан уразаларыбызны, кылган гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итсен, үзенең рәхим-шәфкатеннән ташламасын иде. Аллаһ исемен зикер итеп, күңелләребез белән бары Корьәнгә, иманга ашкынып үткән рамазан ае савапларын күрергә язсын. Яхшы гамәлләр генә кылып, киләсе рамазан аен да исән-сау, бердәм булып каршы алырга насыйп итсә иде!



10-11 битләр

## Илнур ВӘЛИЕВ: “Зәкят түләмәгән бай – мохтаҗлар өлешен ашаучы ул”

**Зәкят – мөселманның кесәсенә сынау ул! Җитмәсә, һәр елны түләп торырга кирәк, шуңа күрә күп кеше аны үтәргә авырсына. Ә бит зәкяттә – бәрәкәт ачкычы! Моны аңлаган мөселман зәкятен һич түләми калмас. Зәкят түләсәк – малыбыз чистара, арта. Түләмәсәк, киресенчә, бәрәкәте китә.**



2 бит

## ГАЛИЕВ мәчете манарасына ай куелды

## “Аерым янган бик тиз сүнә...” Казан казые Габдулла хәзрәт ӘДЬӘМОВ

12 бит


"ДИН ВӘ МӘГЫЙШӘТ"
газетасын өйгә дә яздырып алырга була.
Почта бүлекчәләренә мөрәҗәгать итегез
Индекс – 16046



### Рөстәм МИҢНЕХАНОВ мөфтиятнең социаль проектлары белән танышты

**Рамазан аенда мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин Татарстан Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнехановны Ярдәм мәчетендә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең социаль проектлары белән таныштырды.** Бирегә Рөстәм Миңнеханов ифтарга килгән иде. Ул биредә урнашкан күзләре күрмәүчеләрне тернәкләндерү үзәген карады, укучылар белән аралашты. Шулай ук Теләче районындагы ТР МДН патронажында эшләүче балалар йортында тәрбияләнүчеләр белән сөйләште. Балалар рамазанда Ярдәм мәчетенә кунакка килгәннәр иде.

Рөстәм Миңнехановны Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, аның беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров, урынбасарлары Илдар хәзрәт Баязитов һәм Рөстәм хәзрәт Хәйруллин озатып йөрде. Илдар хәзрәт үзәк эшчәнлеге турында сөйләде, күзләре күрмәүчеләр өчен тудырылган шартларны күрсәтте. Аннары барча кунаклар ифтар мәҗлесенә җыелды.

### Татарстан мөфтие шәкертләренә иҗазәт тапшырачак

Казанның Тынычлык мәчетендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин үзенең шәкертләренә азанны дөрес әйтү буенча дәресләр бирде. Тиздән шәкертләр мөфти кулыннан диплом гына түгел, азан буенча иҗазәт тә алачаклар. Иҗазәт ул – Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сәхабәләренә һәм Ислам тарихындагы беренче мөәзин Билалга барып тоташучы чылбырны дәвам итүне раслаучы дини документ. Камил хәзрәт Сәмигуллин үзе азан буенча иҗазәтне танылган шәех Габдрәхим Сәет Ликрим бин Нахилдан (Марокка) алган.

Азанны дөрес әйтергә өйрәнүдән тыш, мөфти шәкертләре аны башкаруга кагылышлы гыйлемне дә үзләштерәләр, танылган дин галиме Ибн әл-Габидинның "Рәддүл мохтәр" китабыннан азанга кагылышлы бүлекне укый.

### УРАЗА ГАЕТЕ ҖИТТЕ

**Быел Ураза бәйрәме - Гает көне 17 июльгә туры килә.** Бу көнне Татарстанның барлык мәчетләрендә дә Гает вәгазе иртәнге сәгать 7.00 дә башлана. Төп бәйрәм чарасы Казанның Кол Шәриф мәчетендә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин катнашында уза һәм "Татарстан - Яңа гасыр" каналыннан туры эфирда күрсәтелә. Халыкны бәйрәм намазына илтү өчен башкала җәмәгать транспорты иртәнге 4 сәгать 30 минуттан рейска чыгачак.

# Галиев мәчете манарасына ай куелды





**КАЗАНДА ике гасыр элек төзелгән Галиев мәчетенең яңа манараларына ай куелды. Айны урнаштырганда Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин һәм бер төркем мөселман кардәшләребез дога кылып, тәкбир әйтеп торды. Башкала үзәгендә, Тукай урамында урнашкан Галиев мәчетендә хәзерге вакытта төзекләндерү эшләре алып барыла. Бу мәчет бүгенге көндә Иске татар бистәсендә төзекләндерелми калган бердәнбер гыйбадәт йорты иде.**

Галиев мәчетен элек Бишенче җамигъ мәчет дип тә йөрткәннәр. Ул 1798-1801 елларда сәүдәгәр Муса бин Мөслим бин Мамәш ас-Сәрдәви акчасына төзелгән. 1882-1917 елларда мәчетнең имам-хатыйбы вазифасын күренекле дин эшлеклесе, мөгаллим, җәмәгать эшлеклесе, Оренбург мөфтие Галимҗан Мөхәммәтҗан улы Галиев (Баруди) (1857-1921) башкарган. Әтисе сәүдәгәр Мөхәммәтҗан Галиев белән ул Бишенче җамигъ мәчет каршында аталы "Мөхәммәдия" мәдрәсәсен ача.

Мәчетнең ике катлы таш бинасы урам сызыгына почмак белән урнашкан. Мәчет территориясе XIX гасырда чүкеп ясалган челтәр койма белән әйләндереп алынган була. XVIII гасыр азагында мәчетнең урта өлеше төзелә, аның ике гыйбадәт залы һәм төньягында таррак бер вестибюль бинасы була. Вестибюль белән төп бина ике кыеклы түбә белән каплана.

1882 елда сәүдәгәр Ибраһим Сәгыйть улы Уразаев акчасына мәчет бинасының көньягында янкорма төзелә. 1897 елда исә сәүдәгәрләр Мөхәммәтҗан Ибнәмин улы Галиев һәм Исмәгыйль Гобәйдулла улы Имәнкулов акчаларына мәчет көньякка һәм төньякка таба тагын киңәйтелә. Моннан тыш мәчет күп кыеклы түбә белән каплана, өч ярусլы кече манарасы бераз үзгәртелә, ә көньяк янкормасында сигез кырлы манара куела. Янкормалар фасадлары мәчетнең әүвәлге бина фасадлары белән бер стильдә эшләнгән.

1930 елларда дәүләт карамагына тапшырылганнан соң, Галиев мәчете төрле максатларда файдаланыла башлый: ул кунакханә, Колхозчы йорты булып та хезмәт итә, анда коммуналь хезмәтләр дә кереп урнаша. Шул елларда манарасы җимерелә, интерьеры да сакланып калмый. 1997 елда исә Галиев мәчете кабат мөселманнар карамагына тапшырылды, "Мирас" республика программасына кертелде. Һәм менә быел аның ишекләре кабат мөселманнар өчен ачылачак.

Бу гыйбадәтханә безгә күренекле шәхес Галимҗан Баруди исеме белән бәйле булганга да, иске Казанның иң зур мәчетләренең берсе буларак та бик кадерле. Шулай ук ул татар ислам архитектурасының XVIII гасыр азагы – XIX гасырдагы гүзәл бер үрнәге булып санала.

# Дини куркынычсызлыкны саклау – һәр мөселманның бурычы

**ТАТАРСТАН мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин июль башында Вена шәһәрендә "Дин һәм ышанулар ирегә: үзара хөрмәт һәм аңлашуга булышлык күрсәтү" дип аталган җыелышта катнашты. Әлеге мөһим чарага Европаның куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча оешмасына кергән 57 илдән рәсми вәкилләр, дини оешмалар җитәкчеләре җыелган иде. Алар дини ireккә кагылышлы мәсьәләләрне чишүдә һәм милләт, динара мөнәсәбәтләрне коруда туплаган тәҗрибәләре белән уртаклашты.**

Европаның куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча оешмасы өчен фикер, вөҗдан, дин һәм ышанулар ирегенә хокукларны тормышка ашыру, шулай ук үзара хөрмәт һәм аңлашып яшәүне тәэмин итү төп бурыч булып тора. Оешма тарафыннан 1975 елда кабул ителгән актта: "Оешма эшчәнлегендә катнашучы илләр кеше хокукларын һәм фикер, вөҗдан, дин һәм ышанулар ирегене хөрмәт итәчәк",- дип язылган. Кызганыч, соңгы елларда Европаның куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча оешмасына кергән төрле төбәкләрдә дини ышануларга хокуклар кысылган очраклар, шуның белән бәйле кеше хокукларын бозулар арта. Шул ук вакытта дини хокукларны яклаучы төрле программалар, хокукый адымнар ясала.

Европаның куркынычсызлык һәм хезмәттәшлек буенча оешмасы (ОБСЕ) уздыра торган ике көнлек утырышта фикер алышулар, сөйләшүләр өч сессиядә алып барылды. "Куркынычсызлыкны тәэмин итү максатыннан конфессияара өзлексез диалог өчен шартлар тудыру" дип аталган сөйләшүдә катнашкан Татарстан мөфтие фикеренчә, дини конфессияләр өчен ирек мөһим, әмма бер үк вакытта шундый сорау да куярга кирәк: "һәркемгә чикләнмәгән күләмдә ирек биргәндә, бу террорчы төркемнәр барлыкка килүгә сәбәп булмасмы?!" "Шикле белем алган кешеләрнең дини оешмалар җитәкчеләре булган вакытлар узды. Мөселманнар үзләре үк кирәкмәс идеологияләр белән килүчеләргә каршы. Хәзерге көндә дини куркынычсызлыкны саклау һәр мөселман өчен өстенлекле бер бурыч булырга тиеш", – диде Камил хәзрәт. Үзенең чыгышында ул динара диалоглар коруда Татарстанның тәҗрибәсе зур булуга басым ясады.

# “Мәрҗани йорты”нда Ислам музее ачыла



**ТАТАРСТАН Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы “Мәрҗани йорты”н Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенә тапшырды. Әлеге мәдәни мирас корылмасы Каюм Насыйри урамында урнашкан.**

Мөфтинең беренче урынбасары Рөстәм хәзрәт Батров “Мәрҗани йорты”нда булып, бинаның торышы белән танышты. Биредә Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең Ислам музеен оештыру күзаллана. Шул нияттән дин әһелләре һәм белгечләр тарафыннан музей проекты әзерләнә.

Белгәнебезчә, 2015 ел Татарстан мөфтияте тарафыннан Татар дин галимнәре елы дип игълан ителде. Шушы ел кысаларында татар дин галимнәренә кагылышлы төрле сөйләшүләр, аларның рухына багышлап дога кылу чаралары уздырыла, китаплар бастырыла. Олуг татар дин әһеле Шиһабетдин хәзрәт олуг галимнәр белән очрашкан һәм аның рухын саклаган бинаның да шушы елда дин әһелләренә кайтарылуы һәм биредә Ислам музее оештырылуы бер мәртәбәле эш булыр дип көтелә.



## Изге юлда

**Остаз-мөгаллимә, инсаннарга иманлы юлны табарга булышучы оста нәсыйхәтче Сәйдә Фәесхан кызы Аппакова исеме күпләргә таныш.** Узган гасырның 90 нчы елларыннан башлап ул тирә-ягындагыларга дин-исламыбызны аңлата, бигрәк тә балаларга ислам нигезләрен, халкыбызның буыннан-буынга сакланып килгән әдәп-әхлак кагыйдәләрен төшендерә. Республикабызның массакүләм мәгълүмат чараларында көтеп алган абыстай буларак та ул хөрмәткә лаек.

Бала чагында, үсмерлектә газиз әти-әнисеннән алган дини гыйлемен Россия һәм Татарстаныбыз шәһәрләренә, авылларына, районнарга таратучы дин кардәшебез шушы көннәрдә үзенең 80 яшен тутырды. Тугыз ел гимназияләрдә дин тарихы укытуга башлап нигез салган, барлык үгет-нәсыйхәтләрен туплап, 2013 елны зур тираж белән “Тузмый торган бүләк” китабын чыгарып тараткан Сәйдә абыстай Аппаковага шушы юбилее уңаеннан Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Рәхмәт хаты тапшырылды. “Ватаныбыз, милләтебез өчен киләчәктә дә изгелекләр кылып, хезмәт итүегезне телим. Бергәләшеп динебезне ныгытырга, халкыбызның рухи үсешенә өлешебезне кертергә насыйп булсын!” - диелә мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин кул куйган Рәхмәт хатында. Түгәрәк гомер бәйрәме уңаеннан милләтебезнең ак әбиенә илебезнең төрле төбәкләреннән ихлас котлаулар, чәчәкләр, бүләкләр ява.

# Болгарда мөселман яшьләре җыены үткәрелә

**ТАТАРСТАН мөселманнары Диния нәзарәте 20-26 июль көннәрендә Болгарда Мөселман яшьләре форумын уздыра. Җыенда республикадан һәм Россиянең төрле төбәкләреннән, Кырымнан 100 гә якын яшь кеше катнашыр дип көтелә.**

Әлеге форум төрле төбәкләрдә яшәүче мөселман яшьләре арасында элемтәләр урнаштыруга булышлык күрсәтү, татар халкының рухи мирасы белән таныштыру, республиканың мөхтәрәм дин әһелләре, шәхесләре белән аралашу һәм алардан киңәшләр, сорауларга җаваплар ишетү максатыннан оештырыла. Җыен кысаларында лекцияләр, осталык дәресләре, тренинглар, спорт чаралары, экскурсияләр уздыру каралган.



**Болгар шәһәрендә 26 июльдән 5 августка кадәр тагын бер чара - “Милләт” лагере узачак. Лагерьга Россиянең төрле төбәкләреннән балалар һәм яшүсмерләр җыелачак. Шулай ук Финляндиядән дә балалар килер дип көтелә.**

“Милләт” лагеренең максаты – баланы шәхес итеп тәрбияләү, сәләтен ачу, әхлакый яктан үстерү. Программада татар, төрек, гарәп телләрен өйрәнү, экскурсияләр оештыру, музейларга бару, археологик казу эшләре белән танышу; төрле мастер-класслар, тренинглар, шәхесләр белән очрашулар; спорт чаралары уздыру каралган.

“Милләт” балалар лагерен “Милләт” яшьләр үзәге “Ярдәм” фонды белән берлектә оештыра. Лагерьга барырга теләүчеләрдән гаризалар 20 июльгә кадәр кабул ителә. Элемтә һәм ярдәм итәргә теләүчеләр 8 905 319 97 33 номерына шалтырата ала.

## КЫСКАЧА...

**5-11 нче сентябрь көннәрендә узачак XI Казан мөселман кинофестивале оештыру комитеты 52 илдән 700 фильмны теркәгән инде. Ә конкурс программасына 50 генә кинолента узачак. Кинофестивальдә иң яхшы кыска һәм тулы метражлы фильмнар, иң яхшы анимацион фильм, иң яхшы кыска һәм тулы метражлы документаль кинокартиналар ачыкланачак. Фестивальдә шулай ук Татарстан Президентының “Кино сәнгатендә гуманизм өчен” махсус призы, Халыкара "Тюрксой" оешмасының махсус призы һәм Россия кино тәнкыйтьчеләре гильдиясе премиясе дә тапшырылачак.**

***

Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге хезмәткәре Тимергали хәзрәт Юлдашев “Болгар” радиосында тәравих намазын уздырды. Шулай итеп, беренче мәртәбә татар радиосыннан тәравих намазы яңгырады. Бу радио тыңлаучыларга рамазан ае бүләге булды. Тәравихтан соң хәзрәт дога кылды һәм рамазан аеның фазыйләтләре турында сөйләде. Тәравихка кадәр “Болгар” радиосы хезмәткәрләре ифтар ашы да уздырдылар.

***

**Су спорты буенча дөнья чемпионатына санаулы гына көннәр калып барганда Казанда “Хәләл” җәмгать туклануы юнәлешендә эшләүчеләргә квалификацияләрен күтәрү турында таныклык тапшырылды. Республиканың спортчыларга хезмәт күрсәтергә алынган иң яхшы пешерүчеләре ай дәвамында мөселман ризыклары әзерләргә өйрәнде. Курсларны уздыруда Диния нәзарәтенең “Хәләл” стандарт комитеты вәкилләре дә ярдәм итте, алар хәләл аш-су әзерләгәндә шәригать кануннарының саклануын күзәтеп торды.**

***

Мәккәдәге Хәрам мәчете территориясендә бушлай интернет эшли башлады. Бу уңайлыкның төп максаты – мөселманнарга Хәрам мәчете администрациясе белән онлайн аралашу, үзләрен кызыксындырган сорауларга шунда ук җавап алу мөмкинлеген булдыру. Хаҗилар тәваф кылганда, мәсәлән, аларның мобиль җайланмаларына Кәгъбә тирәли тагын ничә тапкыр әйләнергә киреклеге турындагы мәгълүмат та килеп торачак. Моннан тыш, мөселманнар мәчеттә үк ифтарга заказ бирә, игътикяфка электрон теркәлә ала.

***

**Мәдинәдә яңа аэропорт ачылды, ул Согуд Гарәбстанына һава капкасы булып торачак. Яңа төзелешнең беренче чиратына гына да 12 млрд доллар тотылган. Аэропорт елына 8 млн пассажирны үткәрергә сәләтле. Икенче чиратын сафка бастырганнан соң бу күрсәткеч 18 млн, ә соңгысында 40 млн пассажирга җитәчәк. Халыкара аэропорт Согуд Гарәбстаны принцы Мөхәммәд Бин Габдел Газиз исемен йөртә.**

## Мөфти хәзрәтләре игътикяф кылды

**Рамазанның соңгы ун көнендә Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин Казанның “Тынычлык” мәчетендә игътикяфта булды.** Узган ел да рамазанның соңгы көннәрен ул Татарстаныбызга бәрәкәт, халкыбызга тынычлык, иминлек, үсеш сорап, догалар кылып, Коръән укып мәчеттә уздырган иде.

Игътикяф кешенең үзен бары тик Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кылу өчен аерымлавы дигән сүз. Шулай итеп, кол үзен дөнья эшләреннән өзеп, берәр изге урыннан, мәчеттән чыкмыйча, Аллаһы Тәгаләгә генә гыйбадәт кыла. Игътикяф кылучы кеше турында Рәсүлуллаһ салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: “Игътикяф гөнаһларны тоткарлар (иясен барлык гөнаһлардан саклар) һәм барлык яхшылыкларны да кылган кебек аңа (игътикяф кылучыга) саваплар язылыр” (Ибн Мәҗә, “Сыйам”, 67).

# Ураза гаете – исламдагы өч бәйрәмнең берсе

**Җир-күкләрне яралтып, яңгырлар яудырып, шуның белән безгә барлык җимешләрен дә ризык итеп тәкъдим кылган, безне төрле нигъмәтләре белән бүләкләгән Аллаһы Сүбхәәнәһү вә Тәгаләгә хәмед һәм сәнәләр, барча мактауларыбыз, олуглауларыбыз булса иде. Аллаһы Тәбәракә вә Тәгаләнең хәбибе һәм хак илчесе, бөтен галәмнәргә рәхмәт буларак җибәрелгән сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның хөрмәтле гаиләсенә, барлык сәхабәләренә, сәламнәребез, салаватларыбыз һәм һәртөрле изге догаларыбыз булса иде.**



Хөрмәтле мөселманнар! Һәркайсыгызны бөек бәйрәм – Гаед-фитыр көне белән ихлас күңелдән тәбрик итәм. Гаед-фитыр – Ураза бәйрәмебез барчаларыбызга мөбарәк булып, алдагы елларыбызда да илкөннәребез, җан-тәннәребез тыныч һәм сәламәт булган хәлдә дини һәм дөньяви бәйрәм көннәрен шатлык белән күрергә насыйп булсын. Аллаһы Раббыбыз Изге рамазан аенда тоткан уразаларыбызны, укыган намазларыбызны, кылган изге гамәл-гыйбадәтләребезне кабул итеп, барыбызны да җәһәннәм газабыннан коткарып, Үзенең җәннәтләре белән бүләкләсә иде.

Ураза бәйрәме – бик шатлыклы, сөенечле көн. Ни өчен Ураза гаете сөенечле көн соң? Чөнки Гает көнендә бер Аллаһы Тәгаләгә генә шөкер кылабыз, Изге рамазан аенда тоткан уразаларыбызга, укыган намазларыбызга, кылган изгелекләребезгә шатланабыз һәм кабул булуына өметләнәбез. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: "Санаулы (ураза) көннәрен тәмам итеп, сезгә тугры юл күрсәткәне өчен, Аллаһны олылагыз, шөкер итегез" ("Бәкара" сүрәсе, 185 аять).

Әлхәмдүлилләһ, ай буенча ураза тоттык, тәравих намазларын үтәдек, шуның белән бергә дуслык һәм шатлык мәҗлесләре – ифтарда катнашып, авыз ачтык, хәләл ризыклардан авыз иттек. Ул мәҗлесләребездә һәр көн Коръәни Кәрим аятьләрен тыңлап, тәэсирле вәгазьләр ишетеп күңелләребезне тынычландырдык, иманнарыбызны ныгыттык.




Рамазан гаете – ислам динендә булган 3 бәйрәмнең берсе. Беренче бәйрәм – Ураза бәйрәме, икенчесе – Корбан бәйрәме, өченчесе исә – атна саен килә торган җомга көне. Бәйрәм – шатлык, сөенеч мәгънәсе белән килә. Тагын сорау туа: без бу мөбарәк бәйрәмебезне шатлык һәм сөенеч белән үткәрәбезме соң? Без ул бәйрәмнәрне чын бәйрәм итеп уздырабызмы икән? Яңа елда, туган көннәрдә балаларга, туганнарга, дусларга бүләкләр биреп, тәбрикләп, ялтыравыклы уенчыклар элеп, чыршылар куеп шатлансак та, ислам бәйрәмнәрендә намазлар укып, бернәрсә булмаган кебек өйләргә таралышу дөрес түгел. Борынгылар: "Берәр өммәтнең чынбарлыгын күрергә, белергә теләсәгез, аларның бәйрәмнәрендәге хәлләрен карагыз!" – дигәннәр.

Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләм үзенең хәдисендә болай дип әйтә: "Берберегезгә бүләкләр бирешегез, бер-берегезне сөярсез", – ди. Бүләк бирешү өчен Изге ураза гаете көне иң яхшы форсат түгелмени? Бәйрәм көннәрендә, бигрәк тә балаларыбызны шатландырырга тырышырга тиешбез, чөнки шул бәйрәмнәр яшүсмерләрнең күңелләрендә күркәм тәэсир калдырачак, алар динебезне сөеп, яратып, хөрмәт итеп үсәчәкләр, шушы бәйрәмнәрдә булган матур мизгелләр алар күңелендә мәңгегә калачак.

Газиз туганнар! Мөбарәк рамазан ае безгә ризыкның, суның кадерен белергә, начар гадәтләрдән арынып, нәфесләребезне тыеп, изгелекләр кылырга өйрәтте, сабырлык, миһербанлылык, шәфкатьлелек сыйфатларын тәрбияләде. Әгәр үзебезне мөселман дип саныйбыз икән, рамазан аенда башланган игелекле гамәлләребезне, Аллаһы Раббыбызга шөкер итүләребезне изге ай тәмамлангач та дәвам итсәк иде, гөнаһлы гамәлләрдән, яман гадәтләрдән сакланcак иде, җәмәгать!

Яшь чагында кеше дөньядагы булган байлык артыннан куып, намаз укырга вакытым юк, ди, ә картлык көнендә исә хәтерем начар, буыннарым да авырта, дигән аклануллар табарга тырыша. Адәм баласының гомере кыска бит, күп эшләрне башкарып бетереп тә булмый... Бу дөньяда вакытлыча яшәп барыбыз да сыналабыз, үлем җитү белән киләсе дөньяга күчәбез. Ни кызганыч, адәм баласы күп вакытта үз Раббысын онытып, Аллаһка шөкрана кылуны кичектерә, дөнья һәм ахирәт бәхетеннән үзен мәхрүм итә. Аллаһы Тәгалә Коръәни Кәримдә болай дип әйтә: "Исегездәме, Раббыгыз сезгә: шөкер итсәгез, әлбәттә, сезгә (нигъмәтләремне) арттырачакмын, әгәр дә көферлек кылсагыз, һичшиксез, бирәчәк җәзам бик тә хәтәрдер" ("Ибраһим" сүрәсе, 7нче аять). Димәк, нигъмәтләребез күп булсын, үзебез дөньяда һәм ахирәттә бәхетле булыйк дисәк, иң элек барына да канәгать булырга һәм шөкрана кылырга кирәк. Бу игелекле гамәлләребезгә Аллаһы Тәгалә мохтаҗ түгел. Иң әүвәл үзебез өчен, камиллегебез өчен шөкрана кылырга тиешбез.

Шөкрана кылуның иң беренче билгесе – бөтен галәмнәрнең хуҗасы Аллаһны тану, Аңа иман китерү. Барлык галәмнәрнең Раббысын танымау – иң зур көферлек. Аллаһны танымаучы кеше бу дөньяда Аның нигъмәтләрен башкалар белән тигез файдалана алса да, Аллаһның ахирәттә әзерләнгән барча нигъмәтләреннән мәхрүм кала. Ул бәндәгә җәһәннәм газабыннан башка берни дә юк һәм аның хәлен беркем дә, бу дөньяда тупланган берниндибайлыгы да үзгәртә алмый. Андый кеше Аллаһның бу дөньядагы бер өлеш байлыгына алданып, туксан тугыз өлешеннән мәхрүм кала.

Шөкрана кылуның икенче билгесе — Аллаһ кушканнарны үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәү. Аллаһны танып та, Ул кушканча яшәмәгән кеше, көферлеккә төшмәсә дә, зур гөнаһлы була. Бу бәндә Аллаһның олы нигъмәте булган җәннәтенә җәһәннәм газабы аркылы гына ирешә ала.

Аллаһны танып, Аның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүчеләрнең калебләре чиста, йөзләрендә иман нуры балкып тора. Алар үз тормышларыннан канәгать булала беләләр, шул сәбәпле Аллаһы Тәгалә аларның күңелләренә тынычлык бирә. Андый кешеләр мөлаем йөзле, күркәм сүзле булалар һәм беркайчан да зарланмыйлар. Алар турында Аллаһ Раббыбыз Коръәни Кәримдә болай ди: "Дөреслектә, иман китергән кешеләр: безнең тәрбиячебез – Аллаһ, диярләр, соңыннан тормышта Аллаһ кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәрләр, үлгән вакытларында аларга рәхмәт фәрештәләре иңәр, сез хак мөэминнәр, үлемнән вә ахирәттән курыкмагыз һәм дөньяда калган якыннарыгыз өчен дә көенмәгез, бәлки үзегезгә вәгъдә ителгән җәннәт белән шатланыгыз, диярләр. Сезнең белән дөньяда һәм ахирәттә дусларбыз, сезне адашып һәлак булуыгыздан сакларбыз, үзегезгә хәзерләнгән җәннәттә күңелләрегез ни теләсә, шулар булыр, ягъни анда ни сорасагыз, шул бирелер. Бөтен гөнаһларыгыз ярлыканган хәлдә, Аллаһның җәннәтләренә керерсез", – диярләр ("Фуссыйләт" сүрәсе, 30-32 нче аятьләр).

**► ► *Мөселман бәйрәмнәрендә намаз укыгач, бернәрсә булмаган кебек өйләргә таралышу дөрес түгел. Борынгылар: "Берәр өммәтнең чынбарлыгын күрергә, белергә теләсәгез, аларның бәйрәмнәрендәге хәлләрен карагыз!" – дигәннәр.***

Аллаһы Тәгалә безгә Коръәндә нинди эшләрне кылырга һәм нәрсәләрдән тыелырга куша соң?

Коръәни Кәрим аятьләренең берсенә күз салыйк: "Раббың бары тик Үзенә генә гыйбадәт кылырга кушты" ("Исра" сүрәсе, 23 аять). Бу аятьтә әйтелгәнчә, мөселман булуның төп шарты – Аллаһның барлыгына һәм берлегенә ышанып, Аңа гыйбадәт кылу. Әгәр адәм баласы чын күңеленнән Аллаһка һәм Кыямәт көненә (үлгәннән соң терелүгә һәм Аллаһ каршында хисап бирәчәгенә) ышанса, ул һәрвакыт яхшы булырга, кешеләр күргәндә дә, күрмәгәндә дә аларны рәнҗетүдән, малларын урлаудан, барлык начарлыклардан сакланырга тырышачак. "Чын мөселман нинди була?" – дигән сорауга сөекле Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вәсәлләм: "Чын мөселман шундый була: башка кешеләр аның кулыннан да, теленнән дә, каннары, маллары хакында да имин булырлар", – дигән. Хәдистән күренгәнчә, иманлы адәм һичбер вакытта да, һичкемгә дә теле яки кулы белән зарар китермәс һәм һичкемнең малына иясә канына зыян кылмас.

Аятьнең дәвамы: "Ата-анагызга да игелекле булуыгызны катгый рәвештә боерды. Аларның берсе яки икесе дә сезнең янда картайса, аларга: уф (туйдым сездән), – димәгез; аларны битәрләмәгез; икесенә дә яхшы мөгамәләдә булыгыз". Кадерле ата-аналарыбыз безнең дөньяга килүебезгә сәбәпче булганнар. Безне үстергәндә төрле авырлыкларга түзеп, күркәм тәрбия биргәннәр. Ата-аналарыбызның тырышлыкларын истә тотып, аларга карата һәрдаим игелекле, миһербанлы булырга тиешбез.

Аллаһның Рәсүле салләллаһу галәйһи вә сәлләм үзенең бер хәдисендә әйткән: "Ата-аналарыгызның ризалыгына ирешмичә, Аллаһның ризалыгына ирешә алмассыз", – дигән. Исән булсалар, ата-аналарыбызның хәлләрен белеп, ризалыгын, бәхилләгән алыйк. Әгәр үлгән булсалар, аларның каберләренә барып, кулларыбызны күтәреп: "Йә Раббым, ата-анамның гөнаһларын ярлыкап, аларга рәхмәтеңне ирештерсәң иде", – дип догалар кылыйк. Аллаһ Раббыбыз "Исра" сүрәсенең 24нче аятендә болай ди: "Миһербан һәм түбәнчелек белән алар алдында (күңел) канатларыңны җәй дә әйт: "Раббым, сабый чагымнан алып, алар мине ничек сөеп үстергән булса, Син дә аларга шулай мәрхәмәтле бул, – дип дога кыл".

Хөрмәтле дин кардәшләрем! Һәрберебезнең дә янәшәбездә күршеләребез бар. Туганнарыбызга караганда да ешрак аларга мөрәҗәгать итәбез. Күршеләр белән тыныч-тату тору, аларга яхшылык, игелек кылу – мөселманнарның изге вазыйфасы.

**(Ахыры 5 нче биттә.)**

# Бәйрәм намазы

## Вәгазь

Вәгазь ике өлештән — нәсыйхәт һәм рәсми өлешләрдән тора. Вәгазь бәйрәм намазы укылганчы сөйләнә.

### Бәйрәм намазын үткәрү тәртибе

**Имам мөнбәргә менә һәм вәгазь сөйли.**

Бәйрәм намазы вакыты кергәннән соң, имам намаз вакыты җитүен әйтә һәм мөнбәрдән төшеп, намаз укучыларга рәтләргә тезелергә куша. Имамга шуны истә тотарга кирәк, бәйрәм намазында өстәмә тәкбирләр әйтү мәҗбүри (ваҗиб) гамәл булып тора. Беренче рәкәгатьтә — истигаза укыр алдыннан — өч тәкбир һәм икенче рәкәгатьтә рөкүгъ алдыннан өч тәкбир әйтелергә тиеш. Шулай ук әлеге тәкбирләрнең кирәклеге турында намаз укучыларның исләренә төшерү дә лазем. Ахырдан намаз укыла.

Намаз вакытында имам Коръән аятьләрен кычкырып укырга, «Фатихә» сүрәсеннән соң «амин» сүзен эчтән генә әйтергә тиеш.

Ураза бәйрәме өчен түбәндәге кануни вәгазь тәкъдим ителә.

**БЕРЕНЧЕ ӨЛЕШЕ:**

Бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим.

Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Субхәәнә мән нәүүәра кулүүбәл-гаарифиинә би нуурил-мәгърифәти үәл-иимәән, үә шәрахә судүүрас-садикыйинә би шәрхил-һидәәйәти үәл-гыйрфәән, үә әкрамә гыйбәәдәһүлмүэминиинә би сыйәәми шәһри рамәдаан. Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Субхәәнә мән фәтәхә галәссаимиинә әбүәәбәр-рахмәти үәл-гуфраан, үә галләка галәссаимиинә әбүәәбән-нийрани фи шәһри рамәдаан. Үәгадә лиссаимиинә дүхуулә бәәбин мин әбүәәбил-җинәәни кәмәә әхъбәранәә нәбиййүнәә нәбиййү әәхириз-зәмәән: иннә лилҗәннәти бәәбән йукаалу ләһүрраййәән. Ләә йәдхулүү-һүү илләс-саимүүнә фии шәһри рамәдаан. Шәһру рамәдаанәлләзии үнзилә фииһил-куръәәну һүдәл-линнәәси үә бәййинәәтим-минәл-һүдәә үәл-фүркаан, Аллаһу әкбәру, Аллаһу әкбәр, ләә иләәһә илләллаһу үәллааһу әкбәр, Аллаһу әкбәр, үә лилләәһил-хәмде. Үә әшһәду әлләә иләәһә илләллаһу үәхдәһүү ләә шәриикә ләһүү зүл-гафъүи үәлгуфраан, үә әшһәду әннә Мухәммәдән габдүһүү үә расүүлүһүү. Салләллааһу тәгаалә галәйһи үә галәә әәлиһи үә әсхәәбиһии саләәтән-мүүсыйләтән иләә дәәрил-җинәән.

Әййүһәннәәс, үүсыйикум гыйбәәдәллааһи үә нәфсии әүүәлән-битәкъүәллааһ. Әгуузу билләәһи минә шәйтаанир-раҗиим, бисмилләәһир-рахмәәнир-рахим. Иннәллааһә мәгаллэзиинәт-тәкау үәлләзиинә һүм мухсинүүн. Бәәракәллааһү ләнәә үә ләкүм фил-куръәәнилгазыйим, үә нәфәганәә үә ийййәәкүм бил-әәйәәти үәззикрилхәкиим, иннәһүү һүәл-гафууруррахиимул-җәүәәдүл-кәриимулгалиййүл-газыйиму сәмиигуддугааъә.

Мәгънәсе: «Мәрхәмәтле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыга гына мактау. Аллаһыга якынаючыларның күңелләрен мәгъфирәт вә иман нуры белән нурландырган, тугрыларның күңелләрен һидәят һәм белем белән ачкан, мөэмин колларына рамазан ае уразасын бүләк иткән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Рамазан аенда ураза тотучыларга рәхмәт һәм мәгъфирәт ишекләрен ачкан һәм ут ишекләрен бикләгән зат барча кимчелекләрдән дә пакьтер. Ул ураза тотучыларга җәннәт ишекләренең берсе аша керүне вәгъдә иткәндер. Бу турыда безгә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм хәбәр иткән: «Чынбарлыкта, җәннәтнең бер ишеге бардыр — аңа Раян диелә. Ул ишектән рамазан аенда ураза тотучылардан башка беркем дә кермәс». Аллаһы Коръәндә әйтә: «Рамазан ае кешеләргә тугры юл күрсәтүче, ялганнан хакыйкатьне аера торган дәлилләр белән Коръән иңдерелә башлаган айдыр». Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Аллаһыдан башка илаһ юк. Аллааһү әкбәр! Аллааһү әкбәр! Барча мактаулар Аллаһыга булсын. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә, Аның тиңдәше юк, Ул гафу итүче һәм мәгъфирәт иясе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм рәсүле икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аңа, аның гаиләсенә, сахабәләренә Аллаһы Тәгаләдән булган җәннәт йортларына илтә торган салават ирешсен. Әй кешеләр! Аллаһының коллары, сезгә һәм үземә дә тәкъвалы булырга васыять итәм. Таш белән атылган шайтаннан Аллаһыга сыгынам. Рәхимле, шәфкатьле Аллаһы исеме белән. Аллаһы Коръәндә әйтә: «Чынбарлыкта, Аллаһы тәкъвалылар һәм игелек кылучылар белән бергә». Аллаһы безгә һәм сезгә бөек Коръән аша бәрәкәт бирсен. Барыбызга да аятьләр һәм хикмәтле зикер аша файда китерсен. Чынбарлыкта Ул гафу итүче, рәхимле, юмартлык иясе, олуглык иясе, бөек зат һәм догаларны ишетүче, кабул итүче».

**ИКЕНЧЕ ӨЛЕШЕ:**

Иннәл-хәмдә лилләәһи нәхмәдүһүү үә нәстәгъйиинүһүү үә нәстәгъфирүһүү үә нуъмину биһии үә нәтәүәккәлү галәйһи үә нәгуузү билләәһи миң шүрүүри әнфүсинәә үә миң сәййиәәти агъмәәлинәә мәййәһдииһилләәһү фәләә мүдыйллә ләһүү үә мәй-йүдълилһү фәләә һәәдиә ләһ. Үә әшһәду әлләә иләәһә илләллаһү үәхдәһүү ләә шәриикә ләһ, үә әшһәду әннә Мухәммәдән габдүһүү үә расүулүһ. Аллаһүммә салли үә сәллим галәә җәмигыйльәнбийәәи үәл-мүрсәлиин, үә галәә мәләәикәтикәл-мукаррабиин. Үә галәә гыйбәәдикәссаалихыйин, үә галәә әһли таагатикә әҗмәгыйин, мин әһлиссәмәүәәти үәл-ардыйин. Аллаһүммә гъфир лилмүэминиинә үәл-мүэминәәт, үәл-мүслиминә, үәл-мүслимәәт, әләхъйәәи минһүм үәл-әмьүәәт, үәрхәмнәә мәгаһүм. Үәхшүрнәә мәгаһүм бирахмәтикә йәә әрхәмәр-раахимиин.

Мәгънәсе: «Чынбарлыкта, барча мактау Аллаһыга, без Аны мактыйбыз, Аннан ярдәм сорыйбыз, Аннан гөнаһларыбызны гафу итүен сорыйбыз, Аңа иман китерәбез, Аңа таянабыз. Аллаһыга үзебезнең начарлыкларыбыздан, гамәлләребезнең бозыклыкларыннан сыгынабыз. Кемгә Аллаһы тәгалә һидәят бирсә — аны адаштыручы булмас, ә кемне адаштырса — аны туры юлга күндерүче булмас. Аллаһыдан башка илаһ юк, Ул берәү генә. Аның тиңдәше юк икәнлегенә гуаһлык бирәм. Шулай ук, Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм — Аның колы һәм хак илчесе икәнлегенә гуаһлык бирәм. Аллаһым, бөтен пәйгамбәрләргә, илчеләргә, Үзеңә якынайтылган фәрештәләреңә, Үзеңнең изгелек кылучы колларыңа һәм Сиңа итагать итүче әһелләрнең һәммәсенә — булсыннар алар күк әһелләреннән һәм булсыннар алар җир әһелләреннән — барчасына салават һәм сәлам ирештер. Аллаһым, мөэминнәрне вә мөэминәләрне, мөселманнарны вә мөслимәләрне, алар арасыннан исән вә вафат булганнарын мәгъфирәтең белән гафу ит. Алар белән берлектә безгә рәхимле бул һәм безне Үз рәхмәтең илә алар белән бергә булырга насыйп ит, йә рәхимлеләрнең иң рәхимлесе».



## Хөтбә

Аллаһыга мактаулар (зикерләр) булган хөтбә тирән эчтәлекле бәйрәм намазының шарты булып тора. Хөтбә шулай ук ике өлештән тора. Беренче өлештә Аллаһы Тәгаләгә зикер әйтелә, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмгә, аның гаиләсе әһелләренә, гадел хәлифләргә һәм көрәштәшләренә изге теләкләр, тәшәһһед, диндәшләргә үгет-нәсыйхәт әйтелә, Коръән-Кәримнән өзекләр китерелә. Икенче өлештә, тәкъвалыкның башка рәвешләреннән тыш, имам дингә ышанучылар өчен дога кыла. Хөтбәнең ике өлеше бер-берсеннән имамның бераз утырып торуы белән бүленә.

Хөтбә – бәйрәм намазы укылганнан соң сөйләнә. Хөтбә тәмамлангач, имам мөселман халкын бәйрәм белән котлый, аннары кардәшләр бер-берсенә кул бирешә һәм бер-берсен тәбрикли.

Кануни хөтбә гарәп телендә укыла.

**"Гыйбадәт кылулар һәм дини йолалар уздыру турында Нигезләмә"дән**

# Ураза гаете – исламдагы өч бәйрәмнең берсе

**(Ахыры. Башы 4 нче биттә.)**

Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вәсәлләмнең мәшһүр бер хәдисен искә төшерәсем килә: "Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китергән булса, кунагын хөрмәт итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китергән булса, күршесенә игелек итсен. Кем Аллаһы Тәгаләгә һәм ахирәт көненә иман китергән булса, аңа хәерле сүз сөйләсен, яисә дәшмичә торсын", – дигән.

Динебезне бизәүче гадәтләребезнең берсе – пакьлек. Хөрмәтле Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: "Ислам пакьлек өстендә төзелгән, шуңа күрә пакьләнегез", – дигән. Әй мөселманнар! Бөтен эшләрегездә дә пакь булыгыз. Тәннәрегез, киемнәрегез пакь булган кебек ишегалларыгыз, урамнарыгыз, ашый-эчә торган савыт-сабаларыгыз һәркайсы пакь булсын. Пакьлек – сәламәтлекнең башы. Тәне, киемнәре пакь булган кебек чын мөселманның күңеле дә пакь булырга тиеш. Кешеләрнең иң хәерлесе булырга тырышырга кирәк. Халкыбызның: "Таш атканга да аш ат", – дигән сүзләрен беркайчан да истән чыгармыйк.

Мөхтәрәм мөселманнар! Әгәр туган-тумачаларыбыз, дусларыбыз, күрше-күләннәребез арасында бәлагә юлыкканнары күрсәгез, булдыра алганча, аларга ярдәм итәргә тырышыгыз, чөнки, шәригатебез кушканча, мөселманнар үзара тату, ярдәмләшеп яшәргә тиешләр. Аллаһы Раббыбыз әйткән: «Игелек итүдә, яман эш кылудан сакланууда бер-берегезгә ярдәмләшегез. Гөнаһ кылуда, дошманлык эшләрендә ярдәмләшмәгез. Гөнаһлы булып, Аллаһ каршысында җавап бирүдән куркыгыз. Аллаһның җәзасы бик тә хәтәр булыр» ("Маидә" сүрәсе, 2нче аять).

Газиз дин кардәшләрем! Җәнабел Хак барчаларыбызга да тәүфикъ, һидаять бирсә иде. Дөнья һәм ахирәт бәхетсезлегенә сәбәп булган начар гадәтләрдән ерак булып, аек булып, Аллаһның кушканнарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәргә, камил иман белән дөньядан үтәргә насыйп булса иде.

**Нияз хәзрәт САБИРОВ,
Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе**

# Бәйрәм бүген!

**Г.ТУКАЙ**

*Бар күңеллелек бөтен дөньяда, бар бер ямь бүген!*
*— Нәрсәдән бу? — Мин беләм: бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!*
*Бер мөкатдәс хис белән һәрбер кеше хәйран бүген;*
*Уйный сазым да минем бәйрәм көен: бәйрәм бүген!*
*Арттыра, күрдем, кояш гадәттәгедән балкуын;*
*— Ул киенгәндер! — дидем, бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!*
*Хис итеп һәр җирдә дә бер төрле хуш ис аңкуын;*
*«Ислемай сөрткән икән дөнья!» — дидем, бәйрәм бүген!*
*Яр башыннан тыңладым мин бер суның дулкыннарын:*
*Сөйләшәләр үзара: «Бәйрәм бүген, бәйрәм бүген!..»*
*Тыңладым әкрен генә искәндә бәйрәм көн җилен;*

***

Изге рамазан ае тәмалангач, исламдагы ике зур бәйрәмнең берсе – Ураза гаете үткәрелә. Рәсүлебез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм Мәдинәгә күчеп килгән вакытта андагы халыкның уен-көлке, сый-нигъмәт белән үтә торган ике бәйрәм көне булган. Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: “Аллаһы Тәгалә сезнең бу ике бәйрәмегезне хәерле ике бәйрәмгә алыштырды. Ул – Корбан бәйрәме белән Ураза бәйрәме”.

Мөселман бәйрәмнәре Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәте буенча кертелгән, ә аларны үткәрү тәртибе безгә бик күп хәдисләр аша килеп җиткән.

Бәйрәм көнне ураза тотарга ярамый. Хәдисләргә караганда, Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләм бу көнне күңел ачуларны, балаларның уеннарын тыймаган. Гает намазына барыр алдыннан госел коену, бәйрәмчә киенү, өйдә җиңелчә генә ашап алу, юлда бер-береңне мөселманча сәламләү тиешле, шулай ук мохтаҗларга сәдакахәер өләшү дә хуплана. Ә намаздан кайтучы ир-атларны өйдә тәмле ризыклар әзерләп көтеп торалар. Бәйрәм, кунакка йөрешү өч көн дәвам итә.



# Бәйрәм намазы бәяны

**– Гает намазы кылу ни?**

– Җомга намазы ваҗиб булган кешегә Гает намазлары ваҗиб булыр, җомганың фарыз булуына вә әдасына булган шартлары Гает намазының ваҗиб булуына да шарт. Җомга намазы ваҗиб булмаганнарга Гает намазы ваҗиб түгел вә Гает намазларында хотбә уку сөннәт, намаздан соң укылыр, ләкин җомгада фарыз намаздан әүвәл укылыр.

**– Бәйрәм намазларының вакыты ни вакыт?**

– Гает намазлары кояш чыгып ике аршин кадәре күтәрелгәннән соң азансыз вә икамәтсез ике рәкәгать намаз кылыныр. Рамазан вә Корбан гаетенең намазлары икесе дә бер, һич аермалары юк. Ләкин Корбан бәйрәменең гарәфә көнне иртә намазында сәлам биргәннән соң тәкбир әйтү ваҗиб булып, бу намаздан башлап бәйрәмнең дүртенче көне икенде намазында тәмам булыр. Шул егерме өч вакыт намазларның фарызлары соңында ваҗиб. Моңа тәкбир тәшрикъ диелер.

**– Бу тәкбирнең сыйфаты ничек?**

– Ошбу тәкбирнең сыйфаты сәлам биргәне белән: “Аллааһу әкбәр! Аллааһу әкбәр! Ләәә иләәһә иллаллаһ. Үәллааһу әкбәр! Аллааһу әкбәр! Үә лилләәһил хәмде”, – дию. Бу тәкбирне җәмәгать белән кылган булсын вә ялгыз кылган булсын, кирәк мөсафир вә кирәк хаста булсын, ир вә хатын булсын имамәйн (ике имам) каршында җөмләсенә ваҗиб. Максатчан (белә торып теләп) куйса (үтәмәсә) гөнаһлы булыр, онытып куйса гафу булыныр.

**Гает намазлары ни вакытка кадәре укылыр?**

– Гает намазлары кояш күкнең уртасына җиткәнче, ягъни төш вакытынача кылыныр, ләкин төш вакыты җиткәннән соң кылынмас.

**– Рамазан гаетендә бер гозер белән Гает көнне гает укый алмый калсалар, икенче көнне укылырмы?**

– Рамазан гаетендә әүвәлге көнне бер гозер сәбәпле Гает укымасалар, икенче көнне укулары дөрес булыр.

**– Икенче көнне янә бер гозер булып, укымасалар өченче көн укырлармы?**

– Өченче көн укымаслар, дөрес түгел, шул көенчә калыр.

**– Гает намазларының мөстәхәбләре ниләр?**

– Рамазан бәйрәмендә намаздан әүвәл ашау вә эчү вә Корбан бәйрәмендә ашау вә эчүне гаеттән соңга кичектерү, вә мисвәкләнү, вә госел коену, вә хуш исле майлар сөртенү, вә яңа яки юылган кием кию, вә мәсҗидкә җәяү бару, вә Рамазан гаетенә барганда юлда яшерен тәкбир әйтү, вә Корбан гаетенә барганда кычкырып әйтү мөстәхәб.

**– Гает намазлары ничек укылырлар?**

– Әүвәлән: “Ният иттем ике рәкәгать Рамазан гаете намазын яки Корбан гаете намазын кылырга, оедым ошбу имамга. Аллааһу әкбәр!” – диеп колак кагып кул баглар. Имам вә җәмәгать “сүбхәәнәкә аллааһүммә”не укырлар, соңрак кулларын җибәреп, түбән төшереп, өч мәртәбә: “Аллааһу әкбәр!” – диеп колак кагып, һәр колак какканда кулларны яннарына төшереп, өченче тәкбирдә кул баглarлар, имам булган кеше “Фатиха” вә сүрә укыганы белән рөкүгъкә китмичә янә аякта колак кагып, өч тәкбир әйтеп, һәр тәкбир арасында кулларны яннарына төшереп, соңрак дүртенче тәкбир белән рөкүгъка китеп, сәҗүд вә әттәһиятне вә салаватны укып сәлам бирерләр. Бәйрәм намазлары шулай кылынырлар.

**– Бер кеше бәйрәм намазына имам рөкүгъта вакытта җитешсә ни кылыр?**

– Бер кеше бәйрәм намазына имам рөкүгъта вакытта җитешсә, әгәр имамга рөкүгъка җитешәчәгенә күңеле ышанса, ифтитах тәкбирен вә бәйрәм тәкбирләрен алып, рөкүгъка китәр. Вә әгәр имамга рөкүгъка җитешәчәгенә күңеле утырып җитмәсә, ифтитах тәкбирен алып, рөкүгъка барып, бәйрәм тәкбирләрен рөкүгъта әйтер. Ягъни рөкүгъ тәсбихлары урынына өч мәртәбә “Аллааһу әкбәр!” – дияр. Әгәр тәкбирләрне әйтеп бетермәстән әүвәл имам кыямга торса, ул имамга ияреп торыр, калган тәкбир аннан сякыйть булыр, ул кеше рөкүгъта тәкбир әйткәндә кулларын күтәрмәс.

**– Бер кеше Гает намазының бер рәкәгатенә җитешмәсә, ничек укыр?**

– Бер кеше Гает намазының бер генә рәкәгатенә җитешмәсә, ул кеше имамның сәламеннән соң аякка калкып, “Фатихә” вә сүрә укыганы белән колак кагып, өч тәкбир әйтеп, соңрак рөкүгъ сәҗүд кылып әттәхияткә, утырып сәлам бирер.

**– Имам булган кеше Гает намазында әүвәлге рәкәгатьтә тәкбирләрне онытып, “Фатиха” укый башласа ни кылыр?**

– Имам бәйрәм тәкбирләрен онытып, “Фатиха”ның бәгъзесын яки җөмләсен укыса, соңрак хәтеренә килсә, тәкбирләрне алып “Фатиха”ны яңадан укыр, әгәр “Фатиха” дан соң сүрә дә укыган булса, тәкбирләрне әйтер. Ләкин кыйраәтне кайтармас вә әгәр тәкбирләренең берен онытса, рөкүгъта хәтеренә килсә, аны рөкүгъта каза кылыр. Рөкүгъта каза иткәне тәкбирдә кулларын күтәрмәс.

**Гобәйдулла Мөхәммәд ФӘЙЗИнең**
**“Мөфәссаль гыйльме хәл”**
**китабыннан**

# Шәүвәл ае уразасы

Һиҗри календарьда Изге рамазан аен шәүвәл ае алыштыра. Бу айның беренче көнендә без Ураза бәйрәмен билгеләп үтәбез. Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: “Рамазан уразасыннан соң шәүвәл аенда алты көн ураза тотучыга ел дәвамында ураза тоткан кебек савап булыр, чөнки безнең шәригатебездә бер изгелеккә ун өлеш саваптан ким булмас. Исәпләсәк, утыз көнгә өч йөз, алты көнгә алтмыш көн ураза булыр”.

Шәүвәлдәге уразаны рәттән алты көн итеп тә, яисә ай буена чиратлаштырып та тотарга була. Хатын-кызларга башта рамазан аенда калдырган уразаларын тоту хәерле. Рамазаннан калган бурыч ваҗиб санала. Ә шәүвәл аендагы ураза сөннәт булып тора. Шуңа күрә алдан фарызны үтәргә, аннары гына өстәмә гамәлне башкарырга кирәк.

“Мөбарәк кичәләрнең, айларның фазыйләтләре” китабында (“Иман” нәшрияты) шәүвәл ае уразасының фазыйләтләре турында болай диелә: “Бер кеше шәүвәл аенда алты көн ураза тотса, аңа түбәндәге әҗерләр булыр:

– беренче көнне ул кемсәнең кырык еллык гөнаһысы ярлыканыр, Аллаһы Тәгалә ул кемсәгә гамәл дәфтәрен Кыямәт көнендә уң кулына бирер. Ул кешегә Аллаһы Тәгалә оҗмах хөлләләреннән кырык хөллә кидерер. Ул кемсә өчен кырык дәрәҗә бирелер;

– икенче көн руза тотмак белән җитмеш хаҗ савабы язылыр;

– өченче көн руза тотмак белән ике йөз шәһит савабы язылыр. Бу кемсәнең каберенә һәр көндә йөз фәрештә зиярәт кылыр – Кыямәт көненәчә бу кемсә өчен изгелекләр язырлар;

– дүртенче көн өчен Аллаһы Тәгалә бу кемсәнең дөнья хаҗәтләреннән вә ахирәт хаҗәтләреннән җитмеш хаҗәтен үтәр. һәр көндә бу кемсә өчен җитмеш мең фәрештә мәгъфирәт теләр, ягъни: “Йә, Рабби! Бу бәндәнең гөнаһысын ярлыка”, – дип дога кылырлар;

– бишенче көне белән Аллаһы Тәгалә догасын кабул итәр. Ул кемсәдән кабер газабын күтәрер. Кыямәт көнендә йөзе нурлы булыр;

– алтынчы көн белән бу кемсәгә Аллаһы Тәгалә алтмыш ел руза савабын язар. Әгәр шушы арада вафат булса, шәһит булып үләр.

## ХӘЗРӘТКӘ СОРАВЫМ БАР



**Сезнең сорауга Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе, Апанай мәчете имам-хатыйбы Нияз хәзрәт САБИРОВ җавап бирә:**

*"Кызганычка, безнең яшьлек еллары динсезлектә үтте. Инде хәзер, әлхәмдулиллаһ, намазны, уразаны калдырмаска тырышабыз. Мин, шәүвәл ае уразасын да тоткан кеше ел буе ураза тоткан савап ала, дип укыган идем. Шуны беләсем килә - ул уразаның савабы яшьлектә калган уразаларны каплый микән? Аны, яшьлектә калган уразаларым өчен, дип ниятләү дөрес була микән? Соравыма хәзрәт җавап бирсә иде. Сания Гыйльманова, Казан".*

Хөрмәтле Сания ханым! Аллаһы Тәгалә сезгә үзенең чиксез сәламен, рәхмәтен һәм бәрәкәтен ирештерсә иде. Шәүвәл аенда 6 көн ураза тоту – Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең күркәм сөннәте булып тора, ягъни ул көннәрне ураза тотсаң саваплы буласың, тотмасаң гөнаһ язылмый. Бу сөннәтне үтәүдә зур файда һәм күп әҗер бар. Сөекле Пәйгамбәребез Мөхәммәд саллаллаһу галәйһи вә сәлләм әйткән: «Кем Рамазан аенда ураза тотып, соңыннан шәүвәлдә 6 көн ураза тотса, ул кеше ел буенча ураза тоткан кебек булыр» (Әбү Дауд, Тирмизи). Ләкин шәүвәл аенда 6 көн ураза тоту яшьлектә калган уразаларны каплый алмый, чөнки хәдистә уразаның бөек әҗере турында әйтелгән, тотылмаган уразалар өчен кәффәрат[1] булыр дип язылмаган. Элек тотылмаган фарыз уразаларыгыз өчен ихлас күңелдән тәүбә кылыгыз, Аллаһтан гафу сорагыз.

Шәүвәл аенда ураза тотканда Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәтен үтим дип ниятләргә кирәк. Шәүвәлдәге уразаны рәттән 6 көн итеп тә, яисә ай буена чиратлаштырып та тотарга була. Аллаһы Тәгалә һәркайсыбызга изге гамәл-гыйбадәтләр кылып, киләчәк изге Рамазан айларында да уразаларыбызны тотып, ике дөнья бәхет-сәгадәтенә ирешергә насыйп итсә иде.

[1]Кәффәрат – гөнаһтан арыну өмете белән кылынган яки кылынырга тиешле эш.

## РАМАЗАН АЕ УРАЗАСЫН АҢЛЫ РӘВЕШТӘ БОЗСАҢ...

Рамазан аенда аңлы рәвештә бозган уразаны йолу кәффәрат дип атала. Аңлы рәвештә бозган уразасы өчен кеше ике ай (60 көн) дәвамында өзлексез ураза тотарга тиеш. Әгәр дә бу эш хәленнән килми икән, ул 60 фәкыйрьне иртә һәм кич ашатырга тиеш. Шулай ук акча таратырга яки 60 көн дәвамында бер кешене ашатырга була.

Әгәр дә йолу буларак кеше 60 көн ураза тотуны сайласа, бу очракта уразаны өзлексез тоту мөһим шарт булып тора, ягъни бер көнне дә төшереп калдырырга ярамый. Әгәр дә кеше нигезле яки нигезсез сәбәпләр аркасында бер көн уразаны төшереп калдыра икән, кәффарәт бозылган дип исәпләнә, һәм уразаны яңадан башларга кирәк була.



Бердәнбер искәрмә булып хатын кызларның хәезле вакыты тора. Әгәр дә хатын-кыз уразаны хәез сәбәпле бозса, аның кәффәрате бозылган дип исәпләнми. Хәез вакыты узгач ул уразасын дәвам итәргә тиеш була.

Йолу уразасы вакыты – ике ай. Ай календаре буенча бер айда 29 яки 30 көн була, димәк, ураза 58-60 көн дәвам ителергә мөмкин.

# Уразаның казасы һәм бозган өчен кәффәрате

Уразаны бозу ике төрле булырга мөмкин:

***1. Бер көнгә бер көн ураза тотып, кәффәратен үти торган очрак*** (юлда булучы белә торып нәрсә дә булса ашаса, үзе теләмичә косса, хатын-кызда кан китү булса, ир кеше хатынын кочаклау сәбәпле нәҗесләнсә, таң атып та, атмаган дип сәхәр ашаса, кояш батмыйча, баткандыр дип авыз ачылса).

Риваять кылынганча, Әсма бинте Әбү Бәкер, Аллаһ алардан разый булса иде: "Пәйгамбәр галәйһиссәлам исән чагында болытлы көннәрнең берсендә без ифтар кылдык. Соңрак кояш күренде. Без Һишамнан: "Безгә уразаны каза кылыргамы?" – дип сорадык. Ул: "Әйе. Бу очракта уразаны каза кылырга кирәк", – дип җавап бирде", – дигән (Бохари).

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән: "Әгәр ураза тотучы кеше онытылып китеп ашаса, бу – аңа Аллаһы Тәгалә өзерләгән бүләк. Шул сәбәпле ул үзенең уразасын туктатырга һәм каза кылырга тиеш түгел", – дип әйтелә (Дәракутни).

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән: "Әгәр гадәти косу булса, ураза каза кылынмый. Әгәр мәҗбүри косык булса, уразаны каза кылырга кирәк" (Әбү Дауд).

***2. Рәттән 60 көн ураза тотарга яки бер көне өчен 60 кешене ашатырга тиеш булган очрак*** (уразада үз теләге белән ашаса-эчсә, якынлык кылса).

Әбү Һурайра (Аллаһ аннан разый булса иде): "Пәйгамбәр галәйһиссәлам рамазан аенда көндез ашаган бер кешегә бер колны азат итәргә, яки тоташ ике ай рәттән ураза тотарга, яки 60 мескенне ашатырга кушты", – дип тапшырган (Мөслим).

Бервакыт Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына бер кеше килә һәм: "Рәсүлуллаһ! Мин һәлак булдым!" – ди. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Сине нәрсә һәлак итте?" – дип сорый. Ул кеше: "Ураза вакытында мин хатыныма якынлык кылдым", – дип җавап бирә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Синең ирекка җибәрерлек колларың бармы?" – дип сорый. Әлеге ир-ат: "Юк", – ди. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Син ике ай тоташ ураза тота аласыңмы?", – дип сорый. Ир-ат: "Юк", – ди. Пәйгамбәр галәйһиссәлам янә: "Син алтмыш мескенне ашата аласыңмы?" – дип сорый. Ул тагын: "Юк", – дип җавап кайтара. Шуннан соң Пәйгамбәр галәйһиссәлам утыра, күпмедер вакыттан соң хөрмәләр тутырылган кәрҗин китерәләр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам теге кешегә: "Моны ал да сәдака итеп тарат", – ди. Әлеге ир-ат: "Йә, Рәсүлуллаһ! Мин моны үземнән дә ярлырак кешеләргә таратырга тиешме? Мәдинәнең ике тавы арасында булган җирдә минекеннән дә ярлырак гаилә юк бит", – дип әйтә. Шунда Пәйгамбәр галәйһиссәлам тешләре күренеклек итеп көлә һәм аннары: "Бар. Аларны гаиләңә ашат", – ди (Әбү Дауд).



## Уразаның калган көннәрен тутыру

Уразаның калган көннәрен шәүвәл аенда ук тота башлау хәерле. Калган көннәр ничек тизрәк тутырылса – шулкадәр яхшырак. Һәрхәлдә мөселман кешесе аны алдагы рамазанга кадәр тотып бетерергә тиеш. Әгәр кем дә булса, авыруы сәбәпле калган көннәрне икенче рамазанга кадәр тотып бетерә алмаса, ул аны мөмкинлегә булырлык чорга калдыра. Әмма ул бурычы хакында онытмаска тиеш.

Ибне Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде): "Рамазан аенда тотылмыйча алган көннәрне өзлексез яки бүлеп соңыннан каза кылырга мөмкин", – дигән (Дәракутни).

## Күремнән соң уразаны каза кылу

Риваять кылынганча, бер хатын-кыз Гайшә анабыздан (Аллаһ аннан разый булса иде): "Хатын-кызга, күременнән чистаргач, калган намазларын укырга кирәкме?" – дип сораган. Гайшә: "Син Харурданмы әллә? Пәйгамбәр галәйһиссәлам исән вакытта безгә хәездән соң уразаны каза кылырга боера иде, ләкин калган намазларны каза кылырга кушмады", – дигән (Бохари, Тирмизи).

## Мәрхүм өчен уразасын каза кылу

Бер хатын Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килеп: "Минем әнием ураза тотарга нәзер әйтте, әмма нәзерен үти алмыйча үлеп китте. Мин уразаны аның өчен каза кыла аламмы?" – дип сорый. Пәйгамбәр галәйһиссәлам аңа: "Әгәр әниеңнең бурычы булса, син аны түләр идеңме?" – ди. Ул: "Әйе", – дип җавап бирә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Шулай булгач әниең өчен ураза тот!" – дип әйтә.

Риваять кылынганча, Ибне Габбас (Аллаһ аннан разый булса иде): "Башка кеше өчен намаз уку да, аның өчен ураза тоту да рөхсәт ителми. Аның урынына һәр көнне бер мүд бодай бирергә кирәк", – дигән (Нәсәи).

Ибне Гомәр (Аллаһ аннан разый булса иде): "Башка кеше өчен берегез дә ураза тотмасын һәм намаз укымасын, берәрегез моны эшләргә теләсә, аның өчен сәдака бирсен", – дигән.

Хәнәфи мәзһәбе галимнәренең фикере буенча, югарыдагы һәм шуңа охшаш хәдисләр нәзер ителгән уразаны башка кеше өчен каза кылырга мөмкин дигән фикергә ишарәли. Үтәлми калган фарыз уразага яисә нәзер ителмәгән уразага килгәндә, аларны башка кеше өчен тоту рөхсәт ителми.

Мәлик (Аллаһ аннан разый булса иде): "Мәдинәдә сәхабәләр яки аларга иярүчеләр арасында берсенең икенчесенә аның өчен намаз укырга яисә ураза тотарга әйтүчене ишетмәдем. Аларның һәрберсе гамәлләрне үзләре өчен үзләре кыла иде", – дигән (Мәлик).

## Гает һәм тәшрик көннәрендә ураза тотарга ярыймы?

Әбү Сәгыйд әл-Худри (Аллаһ аннан разый булса иде): "Пәйгамбәр галәйһиссәлам елның ике көнендә – Ураза һәм Корбан гаетендә ураза тотуны тыйды", – дип әйткән (Бохари).

Сәгъд бине Әбү Вәккас (Аллаһ аннан разый булса иде): "Пәйгамбәр галәйһиссәлам: "Тәшрик көннәре ул – ашау-эчү көннәре һәм шунлыктан бу көнне ураза тотарга ярамый", – дип барысына да әйтергә кушты", – дигән (Әхмәд).

**Нурислам хәзрәт ИБРАҺИМОВның "Рамазан аенда ураза тоту" дигән хезмәтеннән алынды**

ДИН вә Мәгыйшәт

#7 (240) июль 2015/
рамазан – шәүвәл – 1436

# III Республика ифтарында 5 мең кеше катнашты


**"Казан-Арена" стадионында республикада һәм илдә моңарчы тиңе булмаган иң зур ифтар ашы узды. Узган елгы республика ифтарында барлыгы 2,5 мең кеше катнашкан булса, быелгысына 5 мең мөселман чакырулы иде. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте бу ифтарны РФнең Мөселман эшкуарлар ассоциациясе һәм "Казан-Арена" стадионы дирекциясе белән бергәләп оештырды.**




Мөбарәк рамазан ае – гөнаһлардан арыну, рухи яктан пакьләнү, миһербанлылык, шәфкатьлелек һәм юмартлык ае. Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте дә аны "Рамазан – изге гамәлләр ае" шигаре астында уздыруны максат итеп куеп, Республика ифтарына физик мөмкинлекләре чикле кешеләрне, ятим балаларны, мохтаҗ гаиләләрне чакырды. Ифтар мәҗлесендә шулай ук ТР Президенты вазыйфаларын башкаручы Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе, мөфти Камил хәзрәт Сәмигуллин, Россия мөселманнары Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгать Таҗетдин, Дагыстан, Чечня, Казахстан, Мәскәү һәм башка төбәкләрнең Диния нәзарәтләре вәкилләре, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклеләре, сәясәтчеләр, дин әһелләре катнашты.

Ифтарга килгән халык ахшам намазына кадәр "Казан-Арена" стадионының төп экраны урнашкан мәйданда Яшел Үзән районы имам-мөхтәсибе Габделхәмит Зиннәтуллинның Коръән аятьләре укуын, күренекле дин әһелләренең вәгазьләрен тыңлады. Татарстанның баш казые Җәлил хәзрәт Фазлыев, мөфти урынбасарлары Рөстәм хәзрәт Батров, Рөстәм хәзрәт Хәйруллин, Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе Нияз хәзрәт Сабиров, Кол Шәриф мәчете имам-хатыйбы Илфар хәзрәт Хәсәнов һәм башка дин әһелләренең вәгазьләре ислам кыйммәтләренә, изге рамазанда ураза тотуның фазыйләтләре, әҗер-савапларына, өммәтебез бердәмлегенең мөһимлегенә багышланган иде. Мәшһүр мөнәҗәт әйтүчеләр – дагыстанлы Мөхәммәд Шәфи, татар егетләре Ильяс Халиков һәм Динар Шәймардановларның чыгышлары ифтар мәҗлесенә бәйрәм рухы өстәде. "Казан-Арена" стадионы медиа-фасадыннан исә Диния нәзарәте һәм "Хозур" нәшрият йорты тарафыннан Изге рамазанга багышлап әзерләнгән социаль роликлар күрсәтелеп торды.

Ахшам вакыты кереп, авыз ачкач, меңнәрчә мөселман Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин артына басып намаз укыды, Аллаһы Раббыбыздан күпмилләтле илебезнең алга таба да тынычлыкта-татулыкта яшәвен, чәчәк атуын сорап, дога кылды. Намаздан соң мөселманнарны пылау, ит, яшелчә, камыр ризыклары, җиләк-җимешләр, төрле сулар куелган мул табын артына чакырдылар. Оештыручылар әйтүенчә, быелгы зур ифтарга 9 казанда 2,5 тонна пылау пешерелгән. Әле тәҗрибә әллә ни зур булуга карамастан (бу – өченче зур ифтар), мәҗлеснең оешкан төстә, югары дәрәҗәдә башкарылуын, волонтерларның зур ярдәмен әйтеп китү дә урынлы булыр. Камил хәзрәт Сәмигуллин сүзләренә караганда, илебезнең төрле төбәкләреннән кунаклар кабул иткән быелгы ифтарны Федераль ифтар дип санарга да мөмкин, ә анда катнашучылар санына килгәндә – бу әле чик түгел.















# Изге гамәл дәвамлы булсын!

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтендә гадәткә кергән “Рамазан – изге гамәлләр ае” акциясе быел да изгелекләргә бай булды. Сүзем үзебезнең волонтерлар командасының – 80 нән артык егет һәм кызның Изге айдагы эш-гамәлләре турында.**

Болгар җыенын оештыруда ярдәмчеләр кирәк, дип игълан иткәч, командабызга кушылырга теләк белдерүчеләр шактый күп булды. Нигә булмаска, изге гамәлне күңелле итеп башкару мөмкинлеге иде бит ул. Җыенны оештыруда да ярдәм иттеләр, берочтан Болгар җирлегендәге тарихи объектларны манзара кылу мөмкинлеге дә туды. Шулар өстенә яшьләребез үзләренә яңа дуслар тапты. Берсеннән-берсе акыллы, итагатьле мөслимәләрнең, мөселман егетләренең: “Без үзебезгә Аллаһны яраткан дуслар таптык”, - дигән сүзләре генә дә ни тора!

Шул ук актив егет-кызлар “Минем гаиләмнең шәмаиле” акциясе кысаларында уздырылган чараларда да катнашты. Алар әлеге акциянең дәвамы буларак тагын берничә чара оештырырга тәкъдим иттеләр хәтта. Тормышка ашырырга тырышырбыз. Изге гамәл дәвамлы булсын!

“Рамазан – изге гамәлләр ае” акциясенең тагын бер чарасы “Туган авылым” комплексының “Камыр батыр” балалар үзәгендә үтте. Анда Теләче балалар йотында тәрбияләнүче ятимнәр чакырылган иде. “Серле сандык” дип исемләнгән әлеге чарада балалар татар халкының милли киемнәре, китаплары, көнкүреше турында кызыклы мәгълүмат алды, киемнәрне киеп фотоларга төште, “Легоүзәк”тән чәй табынына чыгасылары да килмәде балаларның.

Рамазан аеның иң кызган чоры – республикакүләм ифтарга әзерләнү булгандыр. Яше, карты әлеге чарада катнашып, ярдәм итәргә теләге барлыгын белдерде. Бигрәк тә узган ифтарларда да катнашкан яшьләрнең булуына куандык – алар алдан ук координаторлар итеп билгеләнде. Дини уку йортлары җәйге ялларга китү сәбәпле, аерым командалар җыя алмасак та, “Мөхәммәдия” мәдрәсәсе 34 кешедән торган команда туплап бирде. Тамчыдан күл җыела дигәндәй, 26 июнь көненә 470 волонтер тупланды. Аларның һәрберсе белән аерым аралашып, социаль челтәрләрдә төркемнәр булдырып, әңгәмәләр оештырдык. Берничә көн алдан ифтар узачак “Казан-Арена” стадионына барып, әзерлек эшләрен башкарып кайттык. 20 сәгатькә якын ураза тоту өстенә, шулкадәр зур чараны уздырырга ярдәм иткән яшьләребезнең гамәлләрен Аллаһы Тәгалә кабуллардан кылсын! Иртәнге сигездән килеп, төнге унбердә генә өйләренә таралышты алар. Яшьлек яшьлек инде ул, берсеннән дә “ардык” дигән сүз ишетмәдек.





Шунысын да әйтергә кирәк, ифтар оештыруда Алексеевск, Кукмара, Түбән Кама, Әлмәт, Минзәлә, Бөгелмә, Питрәч, Мөслим, Апас, Кайбыч, Яңа Чишмә, Чирмешән, Саба, Яшел Үзән, Теләче районы яшьләре дә ярдәм итте. Әлеге районнарның мөхтәсибләренә, яшьләр эшләре өчен җаваплы урынбасарларына, һәм, әлбәттә, юл ераклыгына карамыйча, изге гамәл кылу нияте белән килгән барлык мөселман кардәшләребезгә зур рәхмәт!

Тагын бер күңелле күренеш – волонтерлар арасында гаиләләре белән катнашучылар да бар. Бергәләшеп ураза тотып, шундый чараларда Аллаһ ризалыгы өчен гамәл кылу – тату гаилә тормышы алып бару, балаларга әхлак һәм хезмәт тәрбиясе бирүнең бер ысулы түгелмени?!

Рамазан аеның истә калырдай тагын бер вакыйгасы – Казан кирмәнендә “Рамазан турында сөйлә” чарасы булгандыр, мөгаен. Махсус әзерләнгән түштамгалар һәм рамазан ае турында бәян итүче буклетлар таратылды ул көнне. Күп санлы буклет һәм түштамгалар бик тиз таралып бетте. Махсус кәгазьләргә язылган теләкләр нур өстенә нур булды, чөнки үзара тынычлык һәм аңлашып яшәүгә юнәлгән теләкләрне язучыларның географиясе бик киң иде: Кагалым, Уфа, Казахстан, Замбия, Төркия, Тольятти, Томск һәм, әлбәттә, Казан каласыннан төрле телдә теләкләр теркәлде. Һичшиксез, халык телендә Казан, аның халкы, халыкның кунакчыллыгы һәм мөселманнарның Изге рамазан ае булды.




“Рамазан – изге гамәлләр ае” акциясе Казан шәһәрендә генә түгел, республикабыз шәһәр һәм районнарында да гөрләп барды. Кукмара районында, мәсәлән, яшьләр көче белән ташландык чишмә чистартылды. Баксаң, алар җидәү икән! Алга таба бу чишмәне тагын да төзекләндерү ниятләнә. Азнакай мөхтәсибәте яшьләре белән берлектә “Рамазан – изге гамәлләр ае” дип исемләнгән проектлар конкурсы узды. Чараның үзенчәлеге шунда – яшь гаиләләр үзләренең рамазан аен ничек уздырулары турында сөйләп кенә калмыйча, бала тәрбиясенә дә игътибар биргәннәр. Иҗади эшләр арасында төрле паннолар, махсус сәхифәләр, бер цикл тәшкил иткән эшләр, презентацияләр, хәтта тәгамнәр дә бар иде. Аларның барысы да балалар катнашында әзерләнгән, үз эченә тирән мәгънә алган. Ислам дине, рамазан ае, Кадер киче, Коръән, изге гамәлләр кылу, Аллаһның рәхмәтенең чиксезлеге турында балалар үзләре сөйләп бирде.

Ә “Татлы рамазан” чарасы волонтер егет һәм кызларыбызны Бауман урамына җыйды, инде традициягә кергән бу чара шәһәр халкында бер яктан гаҗәпләнү уятса, икенче яктан, алар, рамазан ае турында мәгълүмат алып, бик тә канәгать калдылар.

Актив егет-кызларыбыз әле “Апрель” тернәкләндерү үзәгенә йөрүче балалар өчен дә бәйрәм рухы тудырды. Сәяхәтебез Казан шәһәренең зообакчасына булды. Егермедән артык бала бакчадагы җәнлек-җанварлар белән танышты, тәмле пылау ашады, фотога төште һәм, әлбәттә, зур канәгатьләнү белән өйләренә таралышты.

Рамазан аендагы кызыклы, истә калырдай вакыйгалар менә шулар булгандыр. Чараларны оештыруда күп көч куйган яшьләребезгә чиксез рәхмәтебезне белдерәбез. Изге гамәл кылуның тәмен татырга теләгән егет-кызларны алга таба да аралашып яшәргә һәм эшләргә чакырабыз. Яшьлек ул - искиткеч тәэсирле, бердәмлек – көчле нәрсә, ә чаралардан соң аңлатып бетереп булмаслык кичерешләр кала. Командадагы дусларга карата булган рәхмәт хисләрен, күңел канәгатьлеген изге эштә катнашкан кеше генә татый ала. Яшьләребездә изгелеккә, игелеккә омтылыш сүнмәсен, Аллаһы Тәгалә гамәлләребездән разый булсын! Рамазан рухы ел буена җитеп, киләсе рамазан ае шатлыгын күрергә, аның бәрәкәтенә ирешергә насыйп булсын!






**Айгөл БИКТИМЕРОВА,**
**Диния нәзарәтенең яшьләр эшләре бүлеге җитәкчесе**

# ЗӘКЯТ ТҮЛӘМӘГӘН ӨЛЕШЕН

**Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең "Зәкят" хәйрия фонды генераль директоры Илнур Илдус улы ВӘЛИЕВ һәм аның урынбасары Илнур Мәхмүт улы АЛЬМЕТОВ белән әңгәмәбез зәкят турында һәр мөселман белергә тиешле гап-гади сораулардан башланса да, сөйләшә торгач, байтак яңалык алдым. Әңгәмә газета укучыларга да кызыклы һәм файдалы булыр дип уйлыйм.**

**– Зәкятнең – мал-мөлкәтеңнән мохтаҗларга өлеш чыгаруның мөһимлеге турында нәкъ менә рамазан аенда күбрәк сөйләнә кебек. Моны, зәкятне Изге айда түләп калырга кирәк, дип аңларгамы?**



**Илнур ВӘЛИЕВ:**

– Зәкят ай календаре буенча елына бер тапкыр түләнә һәм фарыз булып бара. Ул рамазанда да, Корбан бәйрәмендә дә, башка айларда да тапшырылырга мөмкин – аерым көне юк. Рамазан аенда дингә игътибар көчәя, зәкят турында сүзләрнең күбәюе, зәкят түләүчеләрнең артуы шуның белән бәйле.



**Илнур АЛЬМЕТОВ:**

– Шәригатьнең бөтен кануннары язып куелган инде аның. Мәсәлән, балигълыкка җитеп, эшкә урнашкач, бераүнең эшләгән акчасы барлык хаҗәтләренә тотканнан соң да артып кала башлады, ди. Беркөнне бу сумма 85 грамм алтын хакына (быел 170 мең сум) җитә һәм бу нисаб дип атала. Менә шушы көнне билгеләп куя да, ай календаре буенча бер ел узгач (354 көн), рамазанга туры киләме ул, зөлхиҗҗәгәме, әллә бүтән айгамы – малының 2,5 процентын зәкят итеп түли.

**– Зәкят – исламның өченче баганасы, моны һәр мөселман белә, ул аны сезнең ярдәмнән башка гына түли алмыймы? Гомумән, "Зәкят" хәйрия фондының вазыйфасы нидән гыйбарәт?**

**Илнур ВӘЛИЕВ:**

– "Зәкят" фонды Татарстан Җөмһүрияте мөселманнары Диния нәзарәте тарафыннан 1998 елда оеша, башта ул ДУМның комитеты буларак эшләп килә, инде хәзер аерым структурага әйләнде. Безнең бурыч – зәкят һәм сәдака акчаларын җыеп, аларны шәригать кануннары буенча мохтаҗларга таратудан гыйбарәт. Димәк, фонд – мохтаҗларның һәм игелек кылучыларның очрашу урыны да.

Кеше үз акчасының кая киткәнен белеп торса гына кабат бирергә киләчәк. Шуңа күрә иң әүвәл зәкят түләүченең ышанычын яулауны максат итеп куйдык. Фондка күпме акча кергән – кая киткән, кемгә таратылган – болар барысы да сайтыбызда (**zakyatrt.ru**) күренә.

Зәкят акчалары кемнәр арасында таратылырга тиеш соң? Бу хакта Коръәни Кәримнең "Тәүбә" сүрәсендә (60 нчы аять) әйтелгән: **"Сәдакалар – фәкыйрьләргә, мескеннәргә, әмир тарафыннан куелган зәкят җыючыларга вә зәкят өчен исламга күңелләре өлфәт хасил иткән кешеләргә: тоткында булган кешеләргә, бурычын түләргә көче җитмәгән бурычлы кешеләргә, ислам дине өчен Аллаһ юлына һәм малсыз калган мөсафирларгадыр, шул күрсәтелгән урыннарга бирмәк Аллаһтан фарыз ителде. Аллаһ белүче вә хөкем итүчедер".**

Сайтның "Ярдәм кирәк" бүлегендә чиратта торучы мохтаҗлар исемлеген элеп куйдык. Анда бу мөселманның нинди проблемасы бар, акча нинди максатка кирәк – барысы да язылган. Зәкят түләүче, шушы исемлек белән танышып, акчасын үзе теләгән кешегә тапшыра ала. Зәкятен ул безнең фондка терминал аша яисә исәп-хисап счетына күчерә дә, аннары шалтыратып, мин фәлән кадәр акча күчердем, фәлән кардәшкә тапшырыгыз, дип әйтә.

Зәкят һәм сәдака акчаларын аерым җыябыз, исәп-хисап счетлары да, касса да аерым. Бу ни өчен шулай? Чөнки кеше гади сәдаканы күпме тели – шуның кадәр, кайчан тели – шул вакытта бирә ала. Ә зәкят – фарыз сәдака, аны Коръәндә әйтелгән кешеләргә тапшырырга кирәк. Аннан соң түләргә тиешле акчаны дөрес исәпләү дә мөһим. Кайбер эшкуарлар, берничә бизнесы булып, үзләре генә исәпли алмагач, киңәш сорап безгә дә мөрәҗәгать итәләр. Без аларга ярдәмгә Голәмалар шурасыннан берәр хәзрәтне җибәрәбез.

**– Шушы ике елда зәкят күләме үзгәрдеме?**

– Күбәйде, әлхәмдулилләһ, зәкят алучылар да күбәйде. 2013 елда без 2 миллион 808 мең сум җыйган идек, ә узган ел 5,5 миллионга якын булды. Быел да мөселман кардәшләребезне икътисади кризис куркытмас, дип уйлыйбыз. Чөнки зәкятне Аллаһы Тәгалә малны чистарту өчен биргән, ягъни акчаңны чыгарып бирәсең, иншә Аллаһ, шуның акчасында бәрәкәт килә. Аннары бу – фарыз гамәл, аны бернигә дә карамастан үтәргә кирәк. Тупланып, бер ел торган акчаңның 2,5 проценты синеке түгел, түләмәсәң, мохтаҗлар акчасын кесәңдә йөрткән, алар өлешеннән үз ихтыяҗыңны канәгатьләндергән булып чыгасың, Аллам сакласын. Кыямәт көнендә аның өчен бик каты җавап бирергә туры киләчәк.

**– Шулай каты буласын бар кеше дә белеп бетерми торгандыр, бәлки...**

– Күрсеннәр, белсеннәр өчен без сайтыбызга бик күп мәгълүмат әзерләп элдек. "Зәкят турында сөйлә" дигән бүлектә, мәсәлән, зәкят түләүнең мөһимлеген Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм хәдисләре, видеоматериаллар аша дәлилләргә тырыштык. Барлык мөселманнар да безнең сайтның барлыгын беләдер, димим. Шуңа күрә быел мәчетләрдә урнаштыру өчен Голәмалар шурасы белән берлектә плакатлар әзерләдек. Анда зәкятнең төп принциплары аңлатыла. Бу плакатлар Казан мәчетләренә, кайбер районнарга таратылды инде. Болгар җыенында Мари, Чувашия, Пензадан килгән мөселманнарга да биреп җибәрдек. Күпме түләргә, нәрсәдән түләргә, кемгә түләргә тиеш, исәп-хисап счетлары – анда бар да аңлаешлы итеп күрсәтелгән.

**– Бу эшкә мәчетләр дә җәлеп ителә, димәк?**

– Әйе, һәр мәчет ул зәкятне җыярга һәм үз мәхәлләсендәге мохтаҗларга таратырга тиеш. Әйтик, Актаныш районында мәчеткә йөри торган бер мохтаҗга ярдәм кирәк, ди. Чыгышы белән Актаныштан булган эшкуар да, гадәттә, зәкятен шул мәчеткә бирә бит инде. Монда Казанда утырып, без ул мохтаҗны да, ул байны да белмибез, ә мөхтәсиб икесенең дә хәлләрен белеп тора. Ул берсенең зәкятен шәригать кушканча урнаштырып, фарыз гамәлен үтәргә булышса, икенчесенең матди хәлен яхшыртырга ярдәм итә ала.

Аллаһ юлында эшли торган кешеләр (фисәбилилләһ) – галимнәр, укытучылар, шәкертләр, ислам динен таратып йөрүчеләргә аерым тукталасым килә, болар да – зәкят тиешле кешеләр. Узган елның сентябрендә без Диния нәзарәте һәм Россия ислам институты белән берлектә зур программа эшләтеп җибәрдек. Казанның һәм республиканың 4 районындагы мәчет-мәдрәсәләрдә коръәнхафизлар балаларга, өлкәннәргә белем бирә башлады, зәкят акчасыннан аларга хезмәт хакы түлибез. Иң әүвәл РИИның коръәнхафизлар әзерләү бүлеге һәм укытучылар белән килешү төзедек. "Зәкят" фонды сайтына кереп карасагыз, анда укытучының исем-фамилиясе, телефоны, күпме кешене ничә сәгать укыткан, күпме акча төшкән – бар да теркәлгән. Хәзер мөгаллимнәр бу эшкә "теләсәм – барам, теләмәсәм – юк" дип, хоббига караган сыман карамый, чөнки укыткан өчен хезмәт хакы ала. Атнасына 3 тапкыр, аена 12көн укыту мәҗбүри, күбрәк укытса, акчасы да күбрәк була. Ә укытуның сыйфатын РИИдан килеп тикшерәләр. 1 сентябрьдән без моны янә тулы куәтенә эшләтеп җибәрергә дип торабыз, Аллаһ теләсә. Хезмәт хаклары зур түгел түгелен – 6 меңнән 20 меңгә кадәр. Иртәдән кичкә кадәр мәчеттә укыту белән мәшгуль егетләр бар, мәсәлән, Буада эш шулай куелган, аларга даими төстә хезмәт хакы түләп барырга уйлыйбыз.

**– Халыкны исламга тартуга, гыйлем бирүгә, "Зәкят" фонды, чыннан да, үзеннән зур өлеш кертә. Сезне бит әле балалар арасындагы викторина уеннарында да еш күрергә туры килә.**

– Викториналарны без былтыр башлаган идек. Иң әүвәл Диния нәзарәте хезмәткәрләре Пәйгамбәребез тормышы буенча, диннең асылы турында татар һәм рус телләрендә 300 ләп сорау әзерләп куйдылар (теләгән һәркем сайтка кереп, алар белән таныша ала), 60 ар сораудан торган 5 вариант. Без менә шул сораулар буенча Казан мәчетләрендә, районнарга чыгып, балалар арасында викторина уздырабыз. 45 минут эчендә балалар билеттагы сорауларга җавап әзерли, аннары хәзрәтләр аларның дөреслеген тикшереп, балларны исәпләп чыгара, барлык сорауларга да дөрес җавап биргәндә 120 балл килеп чыгарга тиеш. Мәктәпләрдә БДИның максималь баллы 100 булса, мөселманча БДИда ул – 120 балл. Узган ел викторинаны башлап кына җибәргән вакытларны яхшы хәтерлибез әле. Бер районында: "Ахыргы Пәйгамбәрнең исеме ничек?" – дигән сорауга да җа-

**ЗӘКЯТ ТҮЛӘҮ**

«ЗАКЯТ» БЛАГОТВОРИТЕЛЬНЫЙ ФОНД «ЗАКЯТ» ИНН/КПП 1655068682/165501001 ОГРН 1091600003153 ОКПО 63107012 р/с №40703810662190000765 (Советское отделение №6669/015 СБ РФ г. Казани) ОСБ БАНК ТАТАРСТАН №8610 г. Казани к/с: 30101810600000000603 БИК:049205603 Юридический адрес:**420111, г. Казань, ул. Лобачевского, д.6 Адрес: 420021 г. Казань, Тукая, д 3**

*Акчаны электрон юл белән күчерү*
*ЯНДЕКС ДЕНЬГИ: 410011881590169 webMoney: R290630662975 Qiwi кошелек: 4890494181569526*
*Терминал аша*
*Киви терминаллары*
*ТРның Электрон хөкүмәт терминаллары*

*Сбербанк банкоматлары*
*Фонд кассасы*
*Хәйрия сәдакасы тартмалары*

**Элемтәгә керү өчен: fondzakyat@yandex.ru;** тел.: (843) 225-33-22

# БАЙ – МОХТАҖЛАР АШАУЧЫ УЛ

вап бирә алмаганнар иде. Быел, әлхәмдүлиллән, Теләче районында 4 бала 120 балл җыйды. Беренчелекне кайсына бирергә белмәгәннән, хәзрәтләр Коръән укытып карадылар. Башка районнарда да эш бара: 95, 89, 72 шәр балл җыялар.

Бер карасаң, викторина – балалар уены гына. Ә максаты нинди? Бала бит сорауны ача, укый, җавабы белән таныша, имтиханга әзерләнә, аны тапшыра. Беренчелеккә чыгып, зур бүләкләр алмасалар да, без аларга нәүмизләнергә ирек бирмибез, кулларына шоколад булса да тоттырабыз. Күңеле булсын да мәчеткә генә йөрсен. Сентябрьдән бу эшне дә дәвам итәргә уйлыйбыз. Хәзрәтләр янә 300 сорау әзерләп куйдылар. Менә шул балалар тора-бара Коръән укырга өйрәнерләр, өммәттәшләребез сафына басарлар, үсеп җиткәч зәкят түләүчеләрдән булырлар, дигән өметтә торабыз.

Балалар йортлары белән дә эшлибез. Диния нәзарәтенең дәгъвәт бүлеге хезмәткәрләре аларга вәгазь сөйлиләр, без тәмтомнар алып барабыз. Күптән түгел генә "Сабыйга" акциясен башлап җибәрдек. Һәр елны изге гамәлләр ае булган рамазанда без барча халыкка шундый тәкъдим белән чыгабыз: үксез сабыйларга акчалата ярдәм итәргә, яисә офиска балалар өчен кирәк-яраклар китерергә була. Аннары аларны үзебез балалар йортларына илтеп бирәбез.

**– Ә зәкят акчасы мохтаҗларга ничек барып ирешә?**

– Моның өчен сайтта күрсәтелгән документларны җыярга кирәк, анда элемтәгә керү өчен телефоннарыбыз да бар. Без ярдәм сорап килгән кешенең мохтаҗ мөселман булуына ышанырга тиеш, шуңа күрә сораулар да бирәбез, кайчакта йортына да барып карыйбыз. Районнардан килгән гаризаларны мөхтәсибнең "әйе, бу кеше, чыннан да, мохтаҗ, йорты начар, гаиләсенең матди хәле авыр..." дигән үтенеч язуы белән кабул итәбез, шулай ышанычлырак була, чөнки без бит аңа бер мөселманның зәкятен тапшырырга җыенабыз.

**– Коръәндә, зәкят акчасы бурычлыларга да тиеш, дип язылган. Хәзер банктан кредит алып, муеннан бурычка батучылар бик күп...**

**Илнур АЛЬМЕТОВ:**

– Юк, аларга зәкят тиеш түгел. Бурычлы дигәндә хәләл бурычы булган кеше күздә тотыла. Безгә, хезмәт хакымны кисттеләр, машина кредитын түли алмыйм, дип елап килүчеләр дә булды. Шундый хәлгә төшүләре кызганыч, билгеле, әмма без аңлатып бирергә мәҗбүрбез: бу шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән максатларда алынган бурычларга гына кагыла.

**– Мохтаҗлардан байларга күчик әле: хәзер бай эшкуар буларак "Forbes" журналына кергән татарлар да бар. Менә алар да зәкят түли башласа, "Зәкят" хәйрия фонды күпкә баерак булыр иде, минемчә...**

**Илнур ВӘЛИЕВ:**

– Сез хаклы, 5,5 миллион сум – республика өчен зур сумма түгел. Зәкят түләргә кирәклекне аңлатып, зур эшкуарларга хатлар да җибәреп торабыз, 500 эшкуарның 4-5 е генә бераз акча күчерә, калганнарыннан берниндн җавап та юк... Беләсезме, кардәшләрне орышырга түгел, ә күбрәк вәгазьләргә кирәк. Әйе, иманы зәгыйфьрәк мөселманга моны үтәве җиңел түгел. Менә карагыз: исламның беренче баганасы шәһадәт – аны чын күңелеңнән әйтсәң – шул җитә; намазның да кыенлыгы юк; гомереңдә бер тапкыр, шактый акча түгел, хаҗга да барып кайтырга була әле; ураза тоту – ашказанына, телебезгә сынау, бик күп мөселманнар ул сынауны да уза. Ә менә зәкят – кесәгә сынау! Җитмәсә, аны һәр елны түләп торырга кирәк, шуңа күрә күп кеше аны үтәргә авырсына. Ә бит зәкяттә – бәрәкәт ачкычы! Моны аңлаган мөселман зәкятен һич түләми калмас. Зәкят түләсәк – малыбыз чистара, арта. Түләмәсәк, киресенчә, бәрәкәте китә.

**Илнур АЛЬМЕТОВ:**

– Шәригать галимнәре табигатьтәге төрле хәвеф-хәтәрләрне, корылыкны зәкят түләмәү аркасында килеп чыга, диләр. Бер хәдистә китерелгәнчә, зәкят түләнми торган җирдә Аллаһы Тәгалә яңгырны да хайваннар дөньясы хакына гына бирә икән. Әгәр барлык хәлле мөселманнар да зәкят түләсә, бездә бер мохтаҗ кеше калмас иде.

**– Ә кайберәүләрнең байлыгы хәләл юл белән тупланмаган булса, зәкят аны чистарта аламы?**

– Юк, зәкят хәрам малны хәләл ясамый, хәрам акчага хәтта мәчет төзергә дә ярамый. Әмма фарызны барыбер үтәргә – зәкятне түләргә кирәк. Аллаһы Тәгалә – Үзе хөкем итүче.

**Әңгәмәне Нәүбәһар КӘБИРОВА язып алды**



# Нәрсә ул зәкят?

**Зәкят ул – мал-мөлкәттән (байлыктан) фәкыйрьләр, мохтаҗлар өчен бирелә торган билгеле бер күләмдәге акча.**

Зәкят сүзе чистарту дип тәрҗемә ителә. Чөнки, беренчедән, зәкят кешеләрнең байлыгын мал-мөлкәт туплау белән бәйле хаталардан һәм ялгышлардан, ярамаган эшләрдән арындыра. Икенчедән, ул кешеләрнең күңелләрен саранлык һәм шәфкатьсезлек кебек начар сыйфатлардан азат итә, зәкят бирү нәтиҗәсендә кешеләр юмартрак һәм мәрхәмәтлерәк була башлый. Өченчедән, зәкят – Аллаһы ризалыгы өчен ният һәм гамәлләреңне пакьләү. Зәкят бирүче ният һәм гамәлләре өчен Аллаһы Тәгалә алдында җавап бирәсен һәрвакыт исендә тота һәм Аның кануннары буенча яши башлый. Дүртенчедән, зәкят җәмгыятьне социаль тигезсезлек аркасында килеп чыга торган канәгатьсезлектән арындыра. Бишенчедән, хәлле кешеләр дә авыр вакытларында ярдәмсез калмаячакларын аңлыйлар.

## Аны кемнәр түләргә тиеш?

Үз акылында һәм балигъ булган җитәрлек мал-мөлкәткә ия һәр мөэмин-мөселман зәкят түләргә тиеш.

## Зәкяттән кергән акчалар кемнәргә түләнә?

**Ярлыларга.** Әбү Хәнифәнең фикере буенча, ярлылар исәбенә нисаб күләмендәге акчасы булмаган кешеләр яки үзенең бу акчаларын (мөлкәтен) көндәлек ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен тотучылар керә. Әгәр дә кешенең матди мөмкинлеге (мөлкәте) нисаб күләмендә генә булса – ул ярлы булып исәпләнә, әмма зәкят сәдакасына өмет итә алмый.

**Мөлкәтсез кешеләргә.** Болар – бернәрсәсе дә булмаган кешеләр.

**Зәкят җыючыларга.** Зәкят җыю һәм аны бүлеп бирү белән шөгыльләнүче кешеләр бу эшкә мөселманнар тарафыннан билгеләнеп куела. Зәкят җыю һәм җыелган сумманы бүлеп бирү – кешеләр алдында да, Аллаһы Тәгалә алдында да зур җаваплылыкка ия.

Бурычлыларга. Болар үз мәнфәгатьләрен кайгыртып, мәсәлән, кием сатып алырга, дәваланырга яки дошманлыкка чик куяр өчен бурычка акча алып торган кешеләр. Үз бурычларын түли алмаган кешеләрнең бурычлары зәкят исәбенә капланырга мөмкин. Ләкин бу шәригать тарафыннан рөхсәт ителгән максатларда алынган бурычларга гына кагыла. Үз көче белән бурычын кайтара алырга сәләтле кеше зәкят итеп җыелган акча ярдәменә исәп тота алмый.

Аллаһы исеме белән эшләнгән эшләргә – исламга өндәү, дәгъвәт кылу, аның фәнни потенциалын ныгыту һәм мөселманнар арасында фетнә чыгара торган каршы як идея һөҗүмнәрен кире кайтару буенча эшчәнлеккә тотыла ала.

**Мосафирларга.** Зәкят акчалары юлда булучы һәм бу вакытта авыр хәлдә калган (мәсәлән, бар акчаларын да югалтып бетергән, талануга дучар булган) мосафирларга ярдәм итү өчен дә кулланыла. Бу вакытта аларның гомуми матди хәле исәпкә алынмый.

## Зәкят түләүнең шартлары

1. Ел дәвамында (ай календаре буенча) билгеле бер мөлкәткә, акчага (нисабка) ия булу. Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм болай дигән: "Ел тәмам булганчы берниндн мөлкәттән дә зәкят алынмыйдыр" (Әбү Дауд). Зәкят ел азагына булган суммадан чыгып түләнә.

2. Зәкят кешегә үзенең көндәлек тормышын тәэмин итәр өчен кирәк булган акчадан (мөлкәттән) алынмый. Монда азык-төлек, кешеләрнең яшәгән йортлары, өй җиһазлары, аларны суыктан һәм эсседән саклый торган киемнәр, эш кораллары, акыл хезмәте белән шөгыльләнүчеләр өчен аларның бу эшләрендә кулланыла торган китаплар һәм көндәлек тормыш өчен зарур булган башка әйберләр күздә тотыла.

3. Зәкят түләүче кешенең *тиешле нияте булу (әлеге ниятә зәкят түләү өчен акчалар бүленгән вакытта ия булу).*

## Зәкятне нинди мөлкәттән түлиләр?

Зәкят алтын-көмештән, сәүдә, җиләк-җимеш һәм яшелчә, маллар (мөгезле эре терлек һәм мөгезле вак терлек), файдалы казылмалар, табылган хәзинәдән, шулай ук кыйммәтле кәгазьләрдән дә түләнә.

# Аерым янган бик тиз сүнә...

**Ислам дине белән безнең ата-бабаларыбыз VIII-IX гасырларда ук таныша башлый. Идел буе ярында урнашкан болгарлар өчен су юлы сәүдә итүнең иң төп чарасы булган. Сәүдәгәрләр дөнья гизгәннәр: төрле илләрне, төрле халыкларны һәм диннәрне күргәннәр. Нәкъ менә Урта Азия белән сәүдә итүчеләр иң беренчеләрдән булып ислам гадәтләре белән танышканнар. Шулай итеп, әкренләп VII гасырда Гарәп ярымутравында барлыкка килгән ислам дине Урта Азия аркылы Әбү Хәнифә мәзһәбе юнәлешендә Идел буена да үтеп кергән.**



Ислам динен кабул итү болгарларның дөньяга карашларын тамырдан үзгәртсә дә, моңарчы яшәп килгән, ләкин шәригать кануннарына каршы килмәгән гореф-гадәтләр дә сакланып калган. Алар буыннан-буынга, атадан-балага күчә килгән. Ләкин барыбызга да мәгълүм булган Октябрь инкыйлабыннан соң, совет җәмгыяте урнаштырылгач, җирлегебездәге дини уку йортлары, мәчетләр җимерелеп, имам вазыйфалары юк ителгәннән соң, әлеге буынара бәйләнешләр әкренләп өзелде, юкка чыкты. XX йөзнең 90 нчы елларында дингә кайту рөхсәт ителгәннән соң, халкыбызның җаны коргаксыган җир шикелле ислам диненең җирлегебезгә үтеп кергән барлык агымнарын да үзенә сеңдерә башлады. Җиргә төшкән орлыкларның нинди уңыш бирәчәген беркем дә алдан әйтә алмаган шикелле, әлеге агымнарның да нинди нәтиҗәләргә китерәчәген беркем дә фаразлый алмады.

***Әгәр без учакта аерым яткан утын кебек эшебезне аерым-аерым алып барсак, сүнеп бетәрбез дә, милләт буларак та юкка чыгарбыз***

Нәтиҗәсе безнең барыбызның да күз алдында. Бер төп алмагачта үскән төрле тәмдәге алмалар шикелле, халкыбыз да тарихи диненнән аерылып, төрле юнәлештә китте. Шунлыктан төрле шәргый хөкемнәр арасында, инану-инанмау мәсьәләләрендә низаг, гауга купты.

Гореф-гадәтләр белән бәйле булган төп методологик мәсьәлә гореф-гадәт шәригать хөкемнәренең нигезе була аламы-юкмы? Гореф-гадәтне кире кагучылар дәлил буларак Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең хәдисен китерәләр: "Кем безнең юлыбызга анда булмаган нәрсәне кертсә, ул кире кагылыр". Әмма дә ләкин бу хәдис бөтен проблемаларны чишми. Беренчедән, ислам дине гарәпләр өчен генә түгел, ә бәлки бөтен дөнья халыклары өчен индерелде. Икенчедән, Җир шарындагы географик шартлар төрле, шуның сәбәпле шәригать хөкемнәре дә йөз процент бер төрле булырга мөмкин түгел.

Һичшиксез, моны фарсы милләтеннән булган имамыбыз Әбү Хәнифә беренчеләрдән булып аңлаган. Шул ук вакытта имам әш-Шәфигый гарәп булса да, Гыйрак җирләреннән Мисырга күчеп киткәннән соң, икенче мәзһәб төзергә мәҗбүр була. Бу галимнәр Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең башка хәдисенә игътибар итәләр: "Кем исламга күркәм сөннәт (гореф-гадәт) кертеп калдырса, аның әҗерен алыр һәм үзеннән соң бу гамәлне кылган кешеләрнең дә әҗерләре аңа булыр. Кем исламга тискәре сөннәт (гореф-гадәт) кертеп калдырса, аның гөнаһысын алыр һәм үзеннән соң бу гамәлне кылган кешеләрнең дә гөнаһлары аңа булыр". Моның нәтиҗәсендә галимнәребез: "Әгәр гореф-гадәт шәригатькә каршы килмәсә, шәригать аны кабул итә", – дигән хөкемне чыгардылар.

Иң күп бәхәс тудырган мәсьәләләрнең берсе – өчесе, җидесе, кырыгы, елы мәҗлесләре. Милләттәшләребезнең кайберләре боларны "дингә зыян сала торган бидгать" дип атыйлар. Шул ук вакытта, тарихыбыздан күренгәнчә, алар динебезне, милләтебезне саклауда мөһим роль уйнаганын беләбез. Кызганыч, җәмһүриятебезнең кайбер төбәкләрендә бу гореф-гадәткә сугыш игълан итеп хәтта: "Без үзебездә бу гадәтне бетердек", – дип горурланучылар да бар.

Районнарның берсендә булган хәл. Мәетне соңгы юлга озату тәртипләре белән бәйле хәдисләрдән дәлил эзләргә яратучы егетләрнең берсе вафат булганнан соң, дус-ишләре аны юып, кәфенләп, җеназа намазын укып зиратка алып киләләр. Шунда аларның арасында күмү тәртибе буенча бәхәс чыга. Берсе: "Бу хәдистә тәртибе менә шулай аңлатыла", – ди. Икенчесе: "Юк, теге хәдистә тәртибе болай аңлатыла", – дип җавап бирә, ә мәет боларның иҗтиһадларының нәтиҗәсен көтеп ята. Нәтиҗәдә гомере буе мәетләрне озатып йөргән бабайны чакырмыйча, мәрхүмне күмә алмыйлар.

Еш бирелә торган бер сорау: "Коръән ашы табынында булган ризыкны капларгамы, юкмы?" Районнарның берсендә бу мәсьәләне район җитәкчесенең диннәр белән элемтә өчен җаваплы булган урынбасары күтәреп чыгарга мәҗбүр булды.

Татарларда таралган гореф-гадәт буенча мөселманнар намазларын укып, тәсбих әйтеп бетергәннән соң, түгәрәккә тезелеп, бер-берсенә сәлам әйтәләр. Моның нигезендә Пәйгамбәребез саллаллаһу галәйһи вә сәлләмнең сөннәте ятса да, аны бөтенесе кабул итми. Шул сәбәпле бер район җитәкчесе, үзен дин белгече санап, имам белән килешеп, намаздан соң мөселманнарның бер– берсенә сәлам бирүен тыя башлый.

Җомга тәртибе буенча да бер катгый карар юк иде. Бер мәчеттә вәгазь сөннәт намазына хәтле, ә башкасында хөтбә белән бергә, сөннәттән соң укылып килде. Боларны яки икесен дә шәригатькә туры килә дип танырга, яки берсен генә калдыру мәсьләсе килеп туды.

Никах-талак мәсьәләсен алсаң, монда һәркем үзен белгеч дип саный. Шартларын, тәртипләрен тикшермичә, һәрбер килгән парга яки никах укый, яки шәригать алдында ир белән хатын булганны аерып җибәрә. Мисал өчен булган хәлне китерә алам: районнарның берсендә бер ирне хәнәфи мәзһәбендә булганы өчен бидгатьче дип гаепләләр. Хатынына: "Синең никахың бу кеше белән дөрес түгел, ирең диннән чыккан", – дип башын әйләндереп, башка кешегә кияүгә биреп җибәрәләр.

Бер авылда бөтенләй куркыныч хәл булды. Авыл мөселманнары җеназа намазы буенча икегә бүленә. Боларның берәүләре, намаз укымаган кешегә җеназа укымыйбыз, дия башлый. Бу очракта иң куркынычы – бер мөселманның икенче мөселманны кяфер дип исәпләве. Бу фикер ияләре башка дин әһелләрен генә түгел, мөселманнарны да имансызлыкта гаепләп, аларның каннарын түгәргә, байлыкларын талап алырга рөхсәт итә. Моның нәтиҗәсендә соңгы 20 ел эчендә бер Дагыстанда гына да утыздан артык имам үтерелде, берничә мөфтине шартлаттылар. Җөмһүриятебездә дә кайгылы вакыйгалар булып алды. Алай гына да түгел, үзләрен тәрбияләп үстергән дәүләтне кяфер дәүләте дип игълан итәләр дә корал күтәреп чыгалар. Аның нәтиҗәләрен бүгенге көндә Гыйрак, Сүрия, Ливия һәм башка дәүләтләрдә мөселманнарның үз араларында барган сугышлар мисалында күрәбез.

***Районнарның берсендә бер ирне хәнәфи мәзһәбендә булганы өчен бидгатьче дип гаепләләр. Хатынына: "Синең никахың бу кеше белән дөрес түгел, ирең диннән чыккан", – дип башын әйләндереп, башка кешегә кияүгә биреп җибәрәләр***

Бүгенге көндә бу мәсьәләләрнең кайберләре вак, җәмәгать алдында искә алырлык түгел дә кебек, әмма, кызганычка, безнең арада болар төрле бәхәс, аңлашылмаучылык тудыра, мөселманнар бер-берләрен шул вак мәсьәләләр аркасында ваххабичылыкта гаепли, бидгатьче дип йөртә. Мондый мисалларны бик күп китерергә була, хикмәт анда түгел, бу мәсьәләләрне чишү юлын табарга кирәк иде.

Шунлыктан әлеге гаугалы, катлаулы хәлләрне чишү Татарстан Диния нәзарәте җилкәсенә төште. 2011 елда Россия Ислам институтында имамнар өчен махсус "Дингә өндәү нигезләре һәм имамның вазыйфалары" исемендә дәреслек хәзерләп бастырылды. Анда түбәндәге мәсьәләләр күтәрелә: мәхәлләне оештыру (менеджмент), аның белән җитәкчелек итү, мәхәлләнең дини, иҗтимагый эшчәнлеге, дини оешмада белем бирү, дәгъвәт мәсьәләләре һ.б.

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин тәкъдиме белән, шул дәреслек нигезендә, Голәмалар шурасы 2013 елда имамнар өчен Низамнамә төзеде. Бу документ казыйлар шурасында тикшерелде, имам-мөхтәсибләр тарафыннан 2015 елның 3 гыйнварында кабул ителде. Шул көннән башлап Татарстан мөхтәсибләре бу Низамнамәне үзләренең районнарында гамәлгә кертә башлады. Бүгенге көндә Татарстан мәхәлләләре үзләренең эшчәнлекләрен менә шуңа нигезләнеп алып баралар. Әлеге Низамнамә бик күп бәхәсләрне чишә. Әлеге документның уңай нәтиҗәләр бирүе, Татарстаннан читтә яшәүче татар-мөселман кардәшләребезнең дә карашын үзенә җәлеп итте. Үз төбәкләрендә шул Низамнамә нигезендә эшчәнлекне оештырырга теләп мөрәҗәгать итүчеләр бар. Татарстан җирлегендә ирешелгән уңай нәтиҗәләрне искә алып, Татарстан Диния нәзарәте бу Низамнамәне башка өлкәләргә дә тәкъдим итәргә әзер.

Сүземне йомгаклап, бер хикмәтле кыйсса китерәсем килә. Бер авылда мәчет картларының берсе мәчеткә йөрүдән туктый. Имам моның хәлен белергә килгәч, аның мич каршында янган утка карап утырганын күрә. Имам мичтәге бер утынны башкалардан аерып куя да бабай янына барып утыра. Утын сүнә башлагач, имам аны яңадан янып торган утыннар янына куша да чыгып китә. Икенче көнне бабай яңадан мәчеткә йөри башлый.

Мөхтәрәм кардәшләр! Әгәр без теге аерым яткан утын кебек эшебезне аерым-аерым алып барсак, сүнеп бетәрбез дә, милләт буларак та юкка чыгарбыз. Раббыбыз Коръән аятьләренең берсендә безгә: "Вәгтасиму биһәблилләһи җәмигау вә лә тафарраку", ягъни: "Бергәләшеп Аллаһ Тәгаләнең җебенә тотыныгыз һәм аерылмагыз", – дип боерып, безне бердәмлеккә өнди. Без татарларга динебезне, телебезне, милләтебезне саклар өчен бердәм булырга кирәк! Әй Раббым, безгә бу бердәмлекне күңелләребезгә салсаң иде. Мәчетләребез бер тәртиптә эшләп барса иде. Безгә динебезне, милләтебезне сакларга ярдәм итсәң иде!

**Габдулла хәзрәт ӘДҺӘМОВ,**
**Казан казые, Россия ислам институты мөгаллиме, Әниләр мәчете имам-хатыйбы**

# Бик салкын буранлы кыш көне, өлкән кешеләр руза тота иделәр...

**Безнең күптән түгел һәммәмезне бик җиңеллек белән укырга-язарга, үземезне танырга өйрәткән бик кадерле Исмәгыйль бабамыз бар иде, ул хәзер бу дөньядан күчте, рухына ошбу кечкенә хикәяне багышлыйм.**

## I

Әнинең: "Һади, син шәп бит иркәм, саламны ныграк итеп төйнәп алып кер дә, аннан соң эшең бетәр авыз ачуга...", – диюе мине яхшы күңелләндерде. Әни теге якка җылы итеп якмакчы була, бу якта авыз ачуга итле аш пешә... Рәхәт! Безнең әти дә һәрвакытта өйнең җылы булуын ярата: "Өй суык булса ул, анда ямь дә юк, кот та юк", – ди торган иде. Ә без шуның уңаена җылы сөеп өйрәнгәнбез инде. Һади абзый салам керткәч, әни түр якның казанына су китереп салды да, пичнә ут төртеп, миңа ягып торырга кушты. Башта кызуы рәхәт булса да, соңга табан, бер җылынгач, бик кыен инде ул пичкә ягу дип әйткән нәрсә – тирлисең, пешәсең, ут чыгуыннан да куркасың. Ләкин әни кушкач "һи"лап тормыйсың – ягасың да ягасың. Бүген дә мин пичне бик нык кыздырдым. Әни үзе дә: "Әһә, углым, бик күп яккансың икән, җитәр инде, әтиең тегермәннән өшеп кайткач, өйне җылыткан өчен сине сөяр инде", – дип чак туктатты.

Теге якта Һади абзый: "Бу Габдеррахман җизни сау булып тора күрсен, бик озаклады тегермәндә, сәхәрдән киткән кеше...", әни: "Аллаһ сакласын, буранда берүзе...", – диешәләр. Минем уема килә: "Сау булсын дигән була имеш! Әти кадерле әти булсын да – сау булмасын; күпергә җитеп киләдер инде... Җирән ат, кичә генә ясаган яңа камыт белән бер йөк ак онны, әти әйтмешли, рәхәтләнеп китеп тарта бугай..." Әти күренми микән, дип тәрәзәгә омтылсам, карарсың тәрәзәдән! Пыяла чәчәк-чәчәк булып бозланган, тышта буран ыжгыра, карларны тәрәзәгә китереп-китереп бәрә, көн дә караңгыланып бара. Пич янында рәхәт тә, ни, минем бит эшем бар әле үти торган: ахшам әйткәнне тыңлап торып, әниләргә хәбәр бирү. Әмма бүген тышта көрт башына менеп азан әйткәнне карап булмый инде. Бик суык вакытларда тәрәзә төбенә басып карый торган идем дә, хәзер анда барырга да куркыныч... Ә, тукта, аш якта әни дә бар, тәрәзәсе дә бер кат. Менә мин тәрәзә төбенә басам да, пыяладагы туңны тын берлән эретеп, күз кадәрле тишек ясалгач карыйм – урамда бернәрсә генә күренер лә! Курка төшәм: әти кайда икән хәзер? Тегермәннең өе эчендә утырадыр инде ул, атка солы биргәндер дә...Бу вакытта әни аш салып йөри, Һади абзый пимасын пичкә кибәргә тыга; әллә ничек икесе дә бик күңелсез йөриләр, эндәшмиләр, тындашмыйлар. Минем дә эч поша: ахшам да күренми, әти дә өйдә юк.

## II

Бүгенге авыз ачуда һичбер, гадәттә була торган, бәйрәм сыйфаты юк. Караңгы төшкәч, "вакыт булгандыр инде", дип, су берлән генә авыз ачтылар. Ашның токмачы берлән шурпасын гына күмәчләп ашадык та ит һәм чәйне әти кайтуга калдырдык. Ашап беткәч, мин амин итмичә торып барам икән. Әни: "һәй, инсафсыз бала! Алай гадәтсез кыланма, шәкердләр кебек кенә бул – аминнеңне ит тә аннан тор!", – дип шелтәли куйды. Мин дә яңадан утырдым да, кулларым берлән битемне каплап, пышылдап кына: "Аллаһуммәр-зукнә ризкан вәсиган хәләлән таййибән – э, э, әни,



"таййибән"нән соң "мин хәйсу"ме инде?" – дип, әнинең ярдәме берлән ахырына кадәрле укып, битне сыйпап, торып киттем. Һади абзый да: "Тәһарәтем бар, мин тәравихка барып килим, җизни кайтса, атын куеп торыр, үзем карармын", – дип чыгып киткән булган иде дә, "күз ачкысыз" булгач, кире кереп, юкәләр тузгатып, әллә нәрсәләр ишә башлады. Өчле лампа күңелсез генә яна, самавыр өметле генә чыжылдый, әни кулына әрә-әрә табак-савыт юа, урамда бер эт улый. Аңардан әни зарлана: "Гыйззәтнең Мальчигедер инде, хәерсез, үз башыңа булгыры", – ди. Һади абзый көйләп кенә сызгырып, үз эшендә...

Кешене белмим – безнең әни көненә әллә ничә мәртәбә намаз укый иде – иртә дә, көндез дә, кич тә. Менә бүген дә ул вак-төяк эше беткәч, тәһарәт төзеп, киштәдән намазлык итеп җәяргә әтинең яңа җиләнен алды да, бишле лампа яндырып, ак якка намаз укырга чыгып китте. Ул чыгып киткәч, мин алай итеп, болай итеп Һади абзыйдан чыбырка үрдертеп алдым. Бик шәп шартлый торган чыбырка иде дә, көтүгә каршы бара торган вакыт булмагач, бик кызыгы да булмады. Мин эш юктан йончып түрле әмәлләр берлән түр як шүрлектән мулла абзыйның (ул хәзер читтә иде) китаплары арасыннан кич табышмаклар укый торган кенәгәсен алып сурәтләрен карый башладым. Ертылып төшкән бер биттә әллә нинди кеше кашык тотып утыра; әмма кызык тадыр инде! Мулла абзый кебек булып читкә китеп йөри башлагач укырмын әле, югалмасын, дип шул сурәтле битне пич артындагы "борынгы китаплар" шүрлегенең ярыгына кыстырып куйдым. Сурәт каравы да туйдырды. "Әни, мине сәхәргә уятыгыз", – дип әйтер өчен әнинең намаз укып беткәнен көтәм дә – юк, укып бетми шул. Тәмам ялыгып беттем. Менә ул амин итте дә хөрмә төшеннән ясаган туксан тугызлы тәсбихне үрелеп кенә тәрәзә янындагы кадакка элде... Беттеме, дисәң – яңадан иелеп утырып кулларын тезенә куйды да, мыңгырдап кына: "Тәбәракәл-ләзи.." не укырга башлады. Шул минутлар һаман күз алдында: мин сандык өстендә аякларымны салындырып, уң кулыма таянып утырганмын, әнинең тавышы гүя мине йоклатыр өчен чыга – күзләрем йомылып та китә, кинәт-кинәт буран ыжылдый, тәрәзә шакылдаган кебек тоела... Капка ачыла... "Әти кайтты!" – дип куркып уянсам – юк, үзем сандыктан маңлаем берлән төшеп китә язганмын икән. Әни һаман намазлыкта утыра, күлмәгенең киң вә озын җиңенә кулын тыгып тоткан да күзләрен сөртә. Миңа карап: "Ят инде, углым Сәлим, күрәсең, йокың бар бит", – диде дә, сулы борынын җиңе берлән сеңгереп алды. "Ә, мин әйтәм, елый икән". Уяныр-уянмас урынымнан кузгалдым да, әнинең муенына барып сарылам: "Әти нишләп кайтмый икән, ә? Буран булгач бүредән куркадыр инде ул, әйе бит, әни?" – дим. Әни мине ике кулы берлән кочаклап түшенә кыса: "Әйе, бәбкәм, әйе... Әй, ходаем, тигезлек, шатлык..., бәхет, дәүләт..., кеше бусагаларына барырга насыйп итмә..., иман...". Тагы әллә нәрсә, әллә нәрсәләр теләп китте. Мин дә әнинең кочагыннан аның йомшак тезенә төшеп йоклап барам икән, бер эссе генә яшь тамчысының битемә төшүеннән сискәнеп китеп, әнинең чыраена караган идем – түгәрәк күлем ташый башлады. "Чү, елама, углым!" – дигән була әни. Шуннан соң мин әнинең: "... минәшшәйтанир-раҗим, бисми... рахмәнир-рахим" (безнең әни әгүзе бисмилләһнең башын эченнән генә әйтә торган иде ахры), дип мине урынга күтәреп салганын белдем. Чынлап йоклар алдыннан теләк телим: "Йә, Рабби, ходаем, әти-әни үлмәсәләр ярар иде... әби дә әллә ничә еллар торсын әле (әй, мин әни кебек оста тели белмидер идем шул – яза белгән булсам, язып укыган булыр идем дә, кая сүң ул) – әти буранда каракларга очрый күрмәсен.... минем камалы бүрек чөйдә эленеп тора микән? Караклар тимәсен...". Шуннан соң сез мине йоклап киткәндер дип уйлый торгансыздыр? Юк әле. Ул ике арада ишек тупсасы тавышы, Рокыя күрше берлә әллә кемнең әнине атнакич тәравих чәенә чакырулары, әнинең теге "эшләре ирегеп, менә бу вакытта кеше чакырып" йөргәннәрне шелтәләве, әти турында кайгырышулар, шайтанның богаулы булуы – болар һәммәсе минем колактан үтеп торалар. Менә мин изеләм, буыннарым йомшый, әллә нинди бер төпсез чокырга оеп төшеп барам икән, сикереп уяныл киттем. Шул вакыт бер юан тавыш тыны-көне беткән сыман сөйли: "... Садыйк кода берлән Сакмарны чыгып киләләр икән, күперне таба алмаганнар, Габдеррахманның (минем әти түгел микән? – түгелдер әле) чанасы берлән аты астында боз уелган, ди, үзе боз... (минем колагым саклан-ды) ...га тотынып калган, ди (ярый...), Аллаһ саклаган...". Мин тизрәк күземне йом! Төштә булса ярар иде, төшемдә булмаса да, ялгыш ишетәмдер әле. Фонарь... волостьтан кеше... мин аръягын ишетергә теләмәдем, зур һәм җылы бишмәткә төренеп мышкылдавымны белдем.

## III

Сәхәр. Әни мине уята. Аяк очында гына самавыр шаулый. Күземне яртылай гына ачып карыйм: чәйне бераз эчкәннәр булырга кирәк, әти өстенә тун салып иркенләп утырган, үзе тирләгән – ит турый. Әзрәк капкалап та җибәрә. Һади абзый бик тәмләп сөяк кимерә. Песи әтинең бер кулына, бер авызына карап авызларын ялаштыра. Әни мине уята, минем йокы ачылмый. "Әй бала, бала! Иртәнчәк елыйсың бит суң, йокла инде рәхәтләнеп, руза тотам дигән була бит, хәсрәт!" – ди. Әнинең соңгы сүзе миңа килешмәде: хәсрәт, имеш. Ит тә тәмле күренә – сикер дә тор мин! Менә бит мин нинди: өлкән кешеләр берлән сәхәр ашыйм, булыр хәсрәт! Төнлә чәй эчүе бик күңелле дә түгел икән лә. Шунда да, өйдә әти булгач, бутенләй икенче рух. Чәй бераз тын үтсә дә, һәммә кешегә дә рәхәт икәне сизелеп тора. Тик ахырга якын үзебезнең "галанский" әтәчнең кычкырып җибәрүе сәхәр ашаучыларны сүзгә керештерде: "Әһә, әтәчләр дә кычкыра башлады – вакыт икән әле. Ашап та бетерәмез инде...". Бу җирдә әни бер оныткан нәрсәсен исенә төшереп, сикереп торып китте. Бераздан кереп: "Сәхиб күрше уятырга кушкан иде – оныткканмын икән. Әл дә яхшы ул үзе торган икән, ди, тынычланды. Көн дә азрак юнәлгән икән". "Ай-һай, ди, әти әйтә, бу – ходаның кодрәте киң лә инде, әнисе. Һич аның хикмәтен белә торган түгелмез... Боз убылып киткәч, мин бөтенләй харап булдым дип уйлаган идем, шул тәкъдир җитмәгәндер инде, он суда батмый икән ул, капчыклар күтәрелеп торалар, шулай итеп, мин дә котылдым лабаса, җирән ат та, мескен, моннан кеше барганчы муены берлән бозга асылыньп торды...". Әни бу сүзләрне күптән ишетеп, әти берлән бер фикердә булган сымак: "Ие, ходаның ярдәме, моннан түбән дуcка-дошманга күрсәтмә, мәүләм! Шунда киемле көенә боз астына кереп китәсе булсаң... Яхшы айларда, яхшы көннәрдә...". Ә, мин әйтәм, төнлә әти тегермәннең өендә булмаган икән, теге, колакка кереп калганнар дөрес икән. Ләкин чын, ни булганын белә дә алмадым: әтидән сорарга да батырчылык кылмадым.

(Ахыры 15 нче биттә.)

# БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘ – ҖИРДӘ ҖӘННӘТНЕҢ ЧАГЫЛЫШЫ

Аллаһның Илчесе салләллаһу галәйһи вә сәлләм: **“Кем Коръәнне укыды, аны өйрәнде, аның белән гамәл кылды, Кыямәт көнендә аның башына нурдан таҗ кидертерләр. Ул таҗның нуры, кояш нуры кебек. Аның ата-анасына шундый кием кидертерләр, бөтен дөнья ул киемнәр бәясенә тормый. Алар: “Без ни сәбәпле болай киендерелдек?” – дип сорарлар, аларга: “Балаларыгыз Коръәнне кулына алу сәбәпле”, -дип җавап бирерләр”**, – диде.



Күркәм гомер итеп, күп балалар һәм оныклар тәрбияләп үстергән, көчләрен тамчы да кызганмыйча илгә, җәмгыятькә үзләреннән зур өлеш керткән, инде ак әби белән ак бабай булып гомер көзләренә кергән парларны күрсәм сөенеп туя алмыйм. Барлык балалары һәм оныклары ислам динендә булып, Аллаһы Тәгалә кушканнарын үтәп, балалары әти-әниләрен хөрмәтләп, туганлык хакын хаклап яшәүче гаиләләр белән аралашкач, күңелгә бары бер уй килә: “Йә, Раббым, мондый үрнәк гаиләләр бездә күбрәк булса иде!”

Мәлбагыш авылы имамы Сәхибҗан абый һәм Миңсылу апа гаиләсе – әнә шундыйларның берсе. Кешеләргә гел игелек кылып яшәгән Сәхибҗан абый, лаеклы ялга чыкканнан соң, дин юлына баса. Ә 2009 елда аны Мәлбагыш һәм Түбән Якый авылларының имамы итеп сайлап куялар. Шул көннән башлап ул авылдашларын иманга чакырып, азан тавышлары яңгырата, дини йолаларны башкара, белемен арттыру өстендә эшли, гарәп язуын өйрәнә. Ике авылда да мәчет булдыруда, мәчетләребезнең халыкка хезмәт итүендә Сәхибҗан абыйның өлеше әйтеп бетергесез. Хәзрәт, мәхәллә имамы – халыкның рухи тәрбиячесе, мөгаллиме. Бу шулкадәр изге һәм җаваплы вазыйфа, мәхәлләдә яшәүче төрле яшьтәге, катламдагы кешеләр белән аңлашып эшләү сорала. Дөньяга бала аваз салса, яшьләр никахлашса, дөньялык гомере тәмам булып, берәр кардәшебез вафат булса, Коръән мәҗлесләре үткәрелсә, авыл халкы иң беренче Сәхибҗан хәзрәт янына килә. Һәр эшкә ихласлык белән, бары бер Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын өмет итеп тотына ул. Күп дини йолаларны тормыш иптәше Миңсылу апа белән бергә башкаралар.

Аллаһы Тәгалә Җир йөзенә җибәрелгән бәндәләрен барысын да бертөрле яраткан. Ләкин тормыш сынауларын төрлебезгә төрлечә биргән. Кемдер күңел ачып, рәхәт тормышта яши, бүген тамагы тук булса, иртәге көне өчен кайгырмый. Аңа шулай кулай, шулай ошый. Ә кемдер яшьтән үк тормыш арбасын җигелеп тарта, үзенә дә, башкаларга да таләпчән, бу тормышта кирәк булган байлыгын да, ихтирамын да маңгай тирен тамызып яулап ала. Сәхибҗан абый әнә шундыйлардан. Сугышка киткән әтисеннән бердәнбер һәм соңгы хат килгәндә, аңа нибары җиде яшь була. Менә шушы яшьтән хезмәт юлы башлана да инде. Җәйләрен көтү көтеп, берсеннән-берсе кечкенә сеңелләре белән калган әнисенә булыша. Укуга хирыслыгы булса да, урман эчендә урнашкан Елгабаш авылыннан Мәлбагыш мәктәбенә дүрт кенә кыш йөреп кала ул. Гаиләне туйдырырга кирәк. Шактый кырыс, сукыр үги әти белән яшәсә дә, күңеле тупасланмый матур табигать кочагында тәмле чишмә суы уртлап көтү көткән үсмернең.

Унсигезе тулгач, өч еллык армия мәктәбен үтеп, тагын да ныгып, чыныгып кайта. Сугыш чоры ятиме, әнисенең дүрт баласы арасыннан берүзе исән калган унсигез яшьлек Миңсылу апаны гомерлек яры итә Сәхибҗан абый. Тормышларны бераз рәтләп булмасмы, дип читкә чыгып киткән яшь гаилә, бәхетне туган яктан эзләргә кирәк икәненә төшенеп, авылга кайтып төпләнә. Асылгәрәй бабай киңәше белән (монысы Миңсылу апаның бабасы,авылның“Әбүгалисинасы” дип искә алалар аны) Миңсылу апаның әнисен дә үз канатлары астына алалар. Бер-бер артлы дөньяга килгән биш баланы тәртипле, иманлы итеп үстерүдә дә, йорт эшләрендә дә әбинең ярдәме зур була.

Ике кашык белән бер савыт оннан башланган гаилә тормышына әкренләп бәрәкәт иңә. Корыч техниканы иярләп, туган ягының басу-кырларында икмәк үстерә, үз куллары белән ике йорт җиткерә гаилә башлыгы. “Тормыш итәргә мине бабай өйрәтте”,– дип рәхмәт хисләре белән искә ала ул Асылгәрәй бабайны.

Үзеңнән соң догачы булырлык балалар калдыру – олы бәхет. **“Кеше үлгәч аның гамәл дәфтәре ябылыр**, – диде Пәйгамбәребез салләллаһу галәйһи вә сәлләм. – **Бары тик өч төрле кешенең савап дәфтәре ябылмас: 1) сәдака, салган күпере, казыган чишмә , коесы; 2) биргән гыйлеме; 3) әти-әнисенә хәер-дога иткән балалар калдырганныкы”.** Биш баланың һәркайсына төпле белем, ипле тәрбия биреп, хезмәттән тәм табып, олыга-кечегә шәфкатьле, игелекле булырга, туганнар хакын хаклап яшәргә өйрәткәннәр алар.

Тормышның шатлык-куанычлары да, хәсрәт-кайгылары да адәм башына төшә. Сәхибҗан абый белән Миңсылу апага да бала кайгысы кичерергә туры килә – 45 яше яңа тулган кызлары Гөлсирин авырып вафат була. Уртак хәсрәт зур гаиләне тагын да ныграк берләштерә, бу вакытлы дөньяның тәмен, якыннарның кадерен белергә өйрәтә...

Бүгенге көндә Сәхибҗан абый иманга юл күрсәткән, дини белем тупларлык зиһен биргән, шушы юлда армыйталмый эшләрлек сәламәтлек, сабырлык биргән Аллаһы Тәгаләгә, авыл мәчетләрен торгызуда ярдәм иткән игелекле егетләргә чиксез рәхмәтләрен укып, булганына шөкер итеп яши. Быел ул 80 нче язын каршылады, хәләле белән бергә яшәүләренә 55 ел, Миңсылу абыстайга да 75 яшь тулды. Районыбыз мөхтәсибәте исеменнән Сәхибҗан абыйны һәм аның гаиләсен олы бәйрәмнәре белән тәбрик итәбез. Алдагы көннәрдә дә тән сихәтлеге, акыл зирәклеге, иман байлыгы белән, бер-берләренең күңел җылысын тоеп, балалар, оныклар куанычын күреп, тигезлектә яшәргә насыйп итсә иде.

***Равил хәзрәт ДӘҮЛӘТ,***
***Азнакай районы Татшуган авылы имамы, имам-мөхтәсибнең нәсыйхәт һәм матбугат буенча ярдәмчесе***

# ӘЛХӘМДҮЛИЛЛӘҺ!

Ул көнне әнинең: “Гаетне йоклап калырга ярамый, балалар, торыгыз!”–дигәнгадәттәгедән ягымлырак тавышына уянып китәсең. Үзе әнә кичтән үк чүпрәгә изеп калдырган камырыннан коймагын да пешереп өлгергән, өстенә бәйрәм көннәрендә генә кия торган матур ситсы күлмәген киеп куйган, йөзе кояштай балкый...

Намаз укымасак, ураза тотмасак та, Ураза бәйрәмен хөрмәтләргә өйрәнеп үстек без. Совет заманы, дәһрилек чоры булса да, авылыбызда дини бәйрәмнәр тыелмады, Гает намазы укырга безгә җыела торганнар иде, ул вакытта әле мәчет юк, иске мәчетне клуб итеп файдаланалар. Менә урамны тутырып килгән бабайлар түр өйгә кереп урнашалар. Миңа, кыз балага ул бүлмәгә керергә рөхсәт юк, кече якта чаршау артындагы сәкегә менеп кунаклыйм да мулла абзыйның мин белмәгән телдәге сүзләрне көйгә салып укыганын тыңлыйм. Берни аңламасам да, мин аның серле дога сүзләре икәнен беләм. Гает намазы укылган авылга бәрәкәт иңәчәк, илдә сугыш чыкмаячак, тамагыбыз тук, өстебез бөтен булачак – әниләр шулай ди...


Аллаһы Тәгалә яшьлеге намазсыз-догасыз үткән буынны Үзе кичерсен инде, күпме гомер әрәмгә үткән. Шулай да Аллаһының барлыгына, берлегенә инанып, кайчан да булса намазга басачагыбызга, Аллаһыдан ярлыкау сорап, башыбызны сәҗдәгә куячагыбызга ышанып яшәдек без. Ул көннәрне көтеп җиткердек менә, әлхәмдүлилләһ. Балаларыбыз өчен бигрәкләр дә сөенәм. Казаныбызның кырыктан артык мәчете хәзер гает намазларында гына түгел, җомга намазларында да яшьләр белән шыгрым тулы. “Көне буе авызыма бер тамчы су, бер валчык икмәк капканым юк”, – дип зарланмыйча, Аллаһының рәхмәтен өмет итеп, тәравих намазларына йөрүчеләр быел да бихисап күп булды. Республика ифтарында меңләгән мөселман Казанның үзәгендә, бөтен шәһәр халкы күз алдында җәмәгать белән намаз укыды. Димәк, без бетмәгән, юкка чыкмаган, безнең пакь динебез – хак динебез шушы җиребездә кабат күтәрелеп, ныгып килә, әлхәмдүлилләһ!

Менә быел да бәйрәм алдыннан – кояш баеп, Гает төне кергәннән соң, Гает намазына кадәр мөселманнар тәкбик әйтерләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мөстафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм сөннәтенә ияреп, госелләнеп, ислемайлар сөртеп, иң матур киемнәрен киеп, ирләребез Ураза гаете намазына мәчетләргә барырлар. Җәмәгать белән ике рәкәгать бәйрәм намазы укылыр. Хатыннары, әниләре, кыз туганнары аларны мул итеп бәйрәм табыннары әзерләп каршы алыр. Динебезгә һәм халкыбызга хас булганча туган-тумачаның, күрше-коланның, карт-корының хәлен белешү, сыйнигъмәттән авыз иттерү, мәрхүмнәребезне дога белән искә алу кебек савaплы эшләрне дә башкарырбыз, иншә Аллаһ.

Аллаһы Тәгалә тоткан ураза-ларыбызны, укыган тәравихларыбызны кабуллардан кылса иде. Ураза бәйрәмен күңел тынычлыгы белән уздырып, калган көннәребезне дә шушы Изге рамазан аендагы шикелле – Аллаһны истән чыгармыйча, Аның кушаннарын үтәп, тыйганнарыннан тыелып яшәүләрне, киләсе рамазаннарны да күрүләрне насыйп итсә иде.

***Мәрьямбану ХАФИЗ***

# 75 ЯШЕҢ МӨБАРӘК БУЛСЫН, ҖӘГЪФӘР ХӘЗРӘТ!




*Казандагы "Ярдәм" мәчетенең "Зур Казан" басмаханәсендә дин әһелләренә шактый ук яхшы таныш булган Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәкнең чираттагы "Ислам һәм гамәлләр" (сорау вә җавап) дигән 51 нче китабы нәшер ителде. Ислам диненең төрле өлкәләренә кагылышлы 219 сорауга Җәгъфәр хәзрәт Изге Коръәннән һәм хәдисләрдән дәлилләр эзләп табып, төпле җаваплар биргән.*

*Бераүнең: "Коръәнне бик авыр ятлыйм. Аның әҗере булырмы икән?"-дигән соравына Җәгъфәр хәзрәт: "Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: "Коръәнне оста укучы кеше хөрмәтле затлар белән бергә булыр. Укуы авыр булып, кат-кат кабатлап укучыга икеләтә савап ирешер", – дип җавап биргән. Пәйгамбәребез галәйһиссәлам Өхед тавы янындагы сугышларда һәлак булган шәһидләрне җирләгәндә, бер кабергә ике мәетне салырга мәҗбүр булуы турында әйтә һәм кабер янында туктап: "Коръәнне кайсысы яттан күбрәк белә иде?" – дип сораган һәм мәетләрнең берсен күрсәткәч, аны икенчесеннән алда кабергә иңдерүне билгеле. Икенче бер хәдисендә Пәйгамбәребез галәйһиссәлам: "Сезнең иң яхшыларыгыз Коръәни Кәримне өйрәнеп, аны башкаларга да өйрәткән кешедер", – дигән.*

*Ә кем соң ул әлеге китапның авторы Җәгъфәр Муллахмәт улы Мөбарәкшин? Җәгъфәр әфәнде 1940 елның 15 июнендә Луганск өлкәсендә, ягъни Донбасста дөньяга килгән. Әтисе Муллахмәт Тәкәнеш өязендәге Тулбай авылы кешесе була. Әнисе Әсмабикә исә Арча өязенең Балтач авылыннан. Татарстанда ачлык булу сәбәпле, Җәгъфәрнең булачак әтисе дә, әнисе дә Донбасска китеп, эшкә урнашалар, шунда табышалар һәм кавышалар. Аларның 5 баласы туа. Тик баштагы өч балалары вафат була. Дүртенче һәм бишенче бала булган Исмәгыйль белән Җәгъфәр генә исән кала. Озакламый сугыш башлана. Аларның әтисе Муллахмәт сугышка китеп, 1942 елда Сталинград янындагы орышта һәлак була.*

*1944 ел – аларның гаиләсе өчен мәхшәр елы. Менә аларны немецлар бер бинага кертеп, шунда шартлатмакчы булалар, әмма ул бина шыгрым тулы булганлыктан, хайваннар йөртә торган вагоннарга төяп, Германиягә озаталар. Барлык көченә Германиягә чабучы бу поездны совет очкычлары да, немецлар да бомбага тота. Бомбаларның берсе паровозга эләгә. Поезд тимер юлдан читкә чыгып ава, вагоннар берсе өстенә берсе менә, төрле тарафтан ыңгырашкан, елаган авазлар ишетелә. Җәгъфәрләрнең бәхетенәдер инде, шул тирәгә Украина урманнарында немецларга каршы сугышучы партизаннар килеп чыга һәм аларны исән-имин килеш бер вагон астыннан тартып алалар.*

*Җәгъфәр намаз укырга әбисе Галиябанудан өйрәнә. Армиядән соң, Җәгъфәр әфәнде Казанга кайта һәм Ленин исемендәге Мәдәният сараендагы сынлы сәнгать (ИЗО) студиясендә рәсем сәнгатен үзләштерә. Ул бирелә Рөстәм Килдебәков, Илдар Зарипов кебек мәшһүр рәссамнардан дәресләр ала, аннары Мәскәүдәге Н. Крупская исемендәге университетны читтән торып тәмамлый. Ул "Казаньстройтранс", «Татколхозстрой» һәм башка оешмаларда рәссам вазифасын башкара. Шул ук вакытта, дөресрәге 1962 елдан Җәгъфәр әфәнде Мәрҗани мәчетенә намаз укырга да йөри башлый. Аннары ул Габделхак мөәзин Хафизовтан, Габделхак хәзрәт Садыйковтан, Габделхак хәзрәт Каюмовтан дәресләр ала. Кабан арты мәчетендә эшләгәндә, Җәгъфәр хәзрәт 35 китапны хәзерге әдәби телгә күчерә.*

*Җәгъфәр Мөбарәкнең 1000 данә тираж белән "Зур Казан" басмаханәсендә нәшер ителгән "Ислам һәм гамәлләр" китабына уңышлар юлдаш булсын, озын гомер насыйп әйләсен. 15 июньдә Җәгъфәр хәзрәт Мөбарәкнең үзенә дә 75 яшь тулды. Әлеге китап аның туган көненә бер һәдия булсын дигән ният тә калабыз.*

*Җәгъфәр хәзрәткә бу юбилее уңаеннан, Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте рәисе урынбасары Рафыйк Мөхәммәтшин да "Рәхмәт хаты" юллады. Анда мондый юллар бар: "Әссәламәгаләйкүм вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкәтуһ! Хөрмәтле Җәгъфәр Әхмәт углы! Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы мөселманнарының Диния нәзарәте рәисе һәм шәхсән үз исемемнән Сезне юбилеегыз белән тәбрик итәм. Милләтебез тормышында алгы сафларда булып, замандашларыбызга белем-тәрбия бирүдә бәһасез өлеш кертүегез өчен олы ихтирам белән рәхмәтемне җиткерәм.*

*Эшләгән изге гамәлләрегез өчен Раббуль Гыйззә Сезнең үзегезгә, гаиләгезгә, якыннарыгызга күңел тынычлыгы, тән сәламәтлеге, бәхет-шатлык, тәүфыйк-һидаять, озын гомерләр насыйп әйләсен! Кылган изгелекләрегез меңе белән үзегезгә әйләнеп кайтсын. Ватаныбыз, милләтебез өчен изгелекләр кылып, күп еллар дәвамында хезмәт итүегезне телим. Бергәләшеп динебезне ныгыту, халкыбызның рухи үсешенә үз өлешебезне кертү насыйп булсын.*

*Ихтирам һәм изге догалар белән Үзәкләшкән дини оешма – Татарстан Республикасы Диния нәзарәте рәисе урынбасары Р. М. Мөхәммәтшин".*

*Шундый ук әһтәлектәге тәбрикнамәне Җәгъфәр Мөбарәккә Ислам динен кабул итүгә 1000 ел исемендәге Казан югары мөселман мәдрәсәсе ректоры Ильяс хәзрәт Җиһаншин да җибәрде.*

***Хатыйп ГӘРӘЙ***

# Бик салкын буранлы кыш көне, өлкән кешеләр руза тота иделәр...

**(Ахыры. Башы 13 нче биттә.)**

Чынаяклар капланды. Әти: "Йә, Аллаһ, йә Рахим, йә Кәрим!", – дип, киң бер сулыш алды. "Хуш, амин итик әнисе! – сәхәр бетте – Бүген егерме икенче сәхәрме инде?", "Шулайдыр инде, җомга көнне башы иде, җомгадан җомга унбиш булыр иде, таң атса янә җомга. Әй, рамазан шәриф айлары үтеп тә бара". "Намазга иртәрәк микән әле?" "Тукта, чыгып карыйм. Сәлим! Әйдә, тышка чыксаң".

Без әни берлән тышка чыктык. Көн ачык, йолдызлар сирәкләнгән, кояш ягында яктырып килә. Урамнан бер кеше сызгыра-сызгыра ат әчерергә китеп бара. Әтәчләр чуылдыйлар. Ул арада көр тавышлы мөәзин бабай азан да кычкырып җибәрде (иртәнчәк тавыш бик шәп ишетелә икән ул). Ләкин азанны ахшамдагы кебек башламый, иң тәүдә ике рәт әллә нәрсә дип кычкырды (бу миңа бик гаҗәп тоелды, мин аны мәктәптә "Хуҗаи сыбьян"ны чыгып, хәлфә иртәнге азанны үземнән әйттереп карый башлагач кына белдем). Без өйгә кереп, әтигә азан әйткәнен белдердек. Ул урынга чалкан төшеп яткан, куларын баш астына куйган да, гадәттә укый торганын укый дип әйтимме, җырлый димме, хәер, ул укый да һәм җырлый да иде. Мин аларны шул вакытук ятлап алган идем:

"Бу дөньяның вафасы юк,
Һаман җөри җафасы чук;
Һич гаһдени вафасы юк,
Каму аквәледер ялан"

Бу – укый торганы. Мин аны аңламыйм да – ул кыен. Ә җырлый торганы – түбәндәге кебек:

"Ай-һай гына гомер, ай үтәсең,
Картайтып ук әрәм итәсең..."

Әтинең: "Кил углым, ят!" – диюенә мин аның янына барып ятам. Ул мине: "Малаюшка, малаюшка", – дип аркамнан сөя дә, торып: "Син, намаз вакыты булган, дип әйтәсеңме?" – дип, тәһарәт алырга чыгып китә.

Мин иртәнчәк уянсам – өй эссе, кояш та яхшы гына җылы төшә. Әни: "Йә, Сәлим, тортордан хәбәр килгән, йокының мазасы киткән. Менә син бүген өч ураза тотарсың!" – дип, пичтән чәйгүн берлән чәйне алып миңа әчерергә хәзерләп йөри...

Рәхәт лә бу кечкенә вакытта!

**Габделгалләм МОРТАЗИН**
**Шура, 1915, №12**
**Фатих ХӘБИБ әзерләде**

# КУЛЧАТЫР

***"Сезнең кайсыгыз явызлыкны күрә, шул аны үз куллары белән туктатсын; моны эшли алмаса, теле белән; моны да булдыра алмаса, йөрәге белән каршылык күрсәтсен. Тик монысы иманның иң йомшак дәрәҗәсе булыр" (Хәдис).***

*Бүген тәравих намазының икенче көне. Озакка сузмыйча гына, мул итеп ифтар ашыннан тәнемә көч һәм сихәт җыйдым да, күп катлы йортыбызның тимер ишеген җиңел генә ачып, урамга атладым.*

*Кичке Казаныбызның күк чите аксил, үзәк өлеше каралыбрак торган яңгыр болытлары белән каплану сәбәпле, кулыма кулчатырны да алдым. Ләкин аны җәеп җибәреп, баш өстемә күтәрергә әле иртәрәк кебек...*

*Чит-ят илләрдән китерелеп, минем кулыма эләккән кулчатырның гадәти булмаган авырлыгы һәр адым саен үзен сиздерен, уңайсызлык хисе уятса да, кичке һаваның салкынча булуы күңелне күтәреп, адымымны җиңеләйтә иде...*

*Сыйфатлы һәм матур итеп төзекләндерү эшләрен башкарып, затлы келәмнәр җәелгән иман йортыбызның гыйбадәт кылу залына иртәрәк барсаң, мәчет намазын да иркенләбрәк укыйсың, урын да беренче рәттән эләгә. Шуңа күрә йөрүчеләрдән бушап калган кичке урамнан, авыз эчемнән салаватлар әйтә-әйтә, ялгызым берникадәр ашыгыч адымнар белән алга атлыйм.*

*Беренче борылыштан соң, миңа каршы килгән урта яшьләрдәге ир заты күзенә чалынды. Аңа игътибар итмичә, шул ук тизлектә атлавымны дәвам иттем. "Дай двадцать рублей!" – дигән тавышка сискәнеп китеп, башымны күтәрсәм, теге бәндә минем каршымда ук басып тора. Өстенә иппе генә утырган костюмнан булса да, аннан аңкып торган аракы исе укшытып җибәрә язды. Соравына җавап бирмичә, берникадәр читкә тайпылдым да, алга атлавымны дәвам иттем. Минем үз максатым, аның үзенекедер инде...*

*Ләкин бераз баргач, артымнан лап-лоп итеп йөгергән тавышка борылып карыйм дисәм, теге адәми зат баш артыма сугып, түбәтәем шуып китте. Мин ярым борылган килеш түбәтәем белән бергә аның кулын эләктердем, бәрхет баритонымның гадәти тон биеклеге белән: "Аллаһу әкбәр!" – дигәннән соң, тупыл башындагы ала каргалар да куркырлык тавыш белән: "Сейчас ты у меня получишь все тридцать!" – дип акырып җибәрдем дә, кулымдагы кулчатырны, ат өстендә һөҗүмгә барган бабаларыбыз коралына охшатып тотып, аны куып киттем. Ул тыныч кына атлап килгән як кулмәкле, түбәтәйле абзыйдан моны көтмәгән иде шикелле. Мондый галәмәттән каушап та калды булса кирәк. Шуңадырмы, башта бик йөгерә алмады. Соңыннан тизлеге арта төшеп, инде шактый шәп җилдерергә керешТе. Әмма эчендәге теге зәхмәт сыекчасының әвеш-түвеш чайпалуыннан аяклары да чатанлый башлады. Ә минем теләк – аны һичшиксез куып җитеп, кулымдагы "коралым" белән җәзалаудан гыйбарәт иде.*

*Юу-у-к! Ачу хисенә бирелеп, фикерләмичә генә гамәл кылырга ярамаганлыгы турында кайдадыр укыганым бар иде. Шулай да бу юньсезнең арт шәрифләренә кулчатыр белән берәрне эләктерәсем килеп китте.*

*Беренче омтылышымда ук уң ягына берне чәпәдем. Ул тиз генә кулы белән кулчатыр төшкән урынны угаларга тотынды. Ә икенче тапкырында кулчатыр белән сул ягына тондырдым! Ул ике кулы белән дә йомшак җирләрен ышкый-ышкый, светофорга да игътибар итмичә, машиналар юлына ташланды. Юлның аръягына чыгып, миннән котылгач, ул киштәләренә аракы һәм сыра шешәләре тезелгән, төне буена эшләүче кибеткә юнәлде.*

*Ә мин, ашыгычлык белән кылынган гамәлләремнән соң кайнаган хисләрем бераз тынычланып, юлның бу ягында басып калдым... Ярый әле, кызулыгым белән аның җилкәсенә бәрмәгәнмен. Аллам сакласын, йөкы артериясен җәрәхәтләп, фаҗигане зураеп китү ихтималы да булган бит... Ә минем максатым – тәравих намазын вакытында башкару гына иде.*

*Юлымда очрап, минем рухи ныклыгымны тикшереп карарга теләүче адәми затларны да Хак Тәгалә, хәрам ризыклар һәм эчемлекләр кулланудан тыеп, һидаятьле, тугры юлга күндерсен иде... Иншә Аллаһ!*

***Мәгариф РАЯНОВ***

# КАЗАН ӨЧЕН АВГУСТ АЕНА НАМАЗ ВАКЫТЛАРЫ

| Көн | Иртәнге намаз | | Кояш чыга | Өйлә намазы | Икенде намазы | Ахшам намазы | Ястү намазы |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | Таң беленә | Мәчетләрдә укыла | | | | | |
| 01.08.2015 | 01:47 | 02:17 | 03:47 | 12:00 | 17:14 | 19:51 | 21:21 |
| 02.08.2015 | 01:49 | 02:19 | 03:49 | 12:00 | 17:12 | 19:49 | 21:19 |
| 03.08.2015 | 01:51 | 02:21 | 03:51 | 12:00 | 17:11 | 19:47 | 21:17 |
| 04.08.2015 | 01:52 | 02:22 | 03:52 | 12:00 | 17:10 | 19:45 | 21:15 |
| 05.08.2015 | 01:54 | 02:24 | 03:54 | 12:00 | 17:09 | 19:42 | 21:12 |
| 06.08.2015 | 01:56 | 02:26 | 03:56 | 12:00 | 17:07 | 19:40 | 21:10 |
| 07.08.2015 | 01:58 | 02:28 | 03:58 | 12:00 | 17:06 | 19:38 | 21:08 |
| 08.08.2015 | 02:00 | 02:30 | 04:00 | 12:00 | 17:05 | 19:36 | 22:06 |
| 09.08.2015 | 00:13 | 02:32 | 04:02 | 12:00 | 17:03 | 19:34 | 22:02 |
| 10.08.2015 | 00:28 | 02:34 | 04:04 | 12:00 | 17:02 | 19:32 | 21:57 |
| 11.08.2015 | 00:38 | 02:36 | 04:06 | 12:00 | 17:00 | 19:29 | 21:53 |
| 12.08.2015 | 00:47 | 02:38 | 04:08 | 12:00 | 16:59 | 19:27 | 21:49 |
| 13.08.2015 | 00:54 | 02:40 | 04:10 | 12:00 | 16:57 | 19:25 | 21:44 |
| 14.08.2015 | 01:01 | 02:42 | 04:12 | 12:00 | 16:56 | 19:23 | 21:40 |
| 15.08.2015 | 01:07 | 02:44 | 04:14 | 12:00 | 16:54 | 19:20 | 21:36 |
| 16.08.2015 | 01:13 | 02:45 | 04:15 | 12:00 | 16:53 | 19:18 | 21:32 |
| 17.08.2015 | 01:19 | 02:47 | 04:17 | 12:00 | 16:51 | 19:16 | 21:28 |
| 18.08.2015 | 01:24 | 02:49 | 04:19 | 12:00 | 16:49 | 19:13 | 21:24 |
| 19.08.2015 | 01:29 | 02:51 | 04:21 | 12:00 | 16:48 | 19:11 | 21:20 |
| 20.08.2015 | 01:34 | 02:53 | 04:23 | 12:00 | 16:46 | 19:08 | 21:16 |
| 21.08.2015 | 01:38 | 02:55 | 04:25 | 12:00 | 16:44 | 19:06 | 21:13 |
| 22.08.2015 | 01:43 | 02:57 | 04:27 | 12:00 | 16:43 | 19:04 | 21:09 |
| 23.08.2015 | 01:47 | 02:59 | 04:29 | 12:00 | 16:41 | 19:01 | 21:05 |
| 24.08.2015 | 01:51 | 03:01 | 04:31 | 12:00 | 16:39 | 18:59 | 21:02 |
| 25.08.2015 | 01:55 | 03:03 | 04:33 | 12:00 | 16:37 | 18:56 | 20:58 |
| 26.08.2015 | 01:59 | 03:05 | 04:35 | 12:00 | 16:35 | 18:54 | 20:54 |
| 27.08.2015 | 02:03 | 03:07 | 04:37 | 12:00 | 16:34 | 18:51 | 20:51 |
| 28.08.2015 | 02:06 | 03:09 | 04:39 | 12:00 | 16:32 | 18:49 | 20:47 |
| 29.08.2015 | 02:10 | 03:11 | 04:41 | 12:00 | 16:30 | 18:46 | 20:44 |
| 30.08.2015 | 02:13 | 03:13 | 04:43 | 12:00 | 16:28 | 18:44 | 20:40 |
| 31.08.2015 | 02:17 | 03:15 | 04:45 | 12:00 | 16:26 | 18:41 | 20:37 |




**Көн саен "Азан" радиосы (radioazan.ru) тапшыруларын "Курай" (73,97 FM) радиосыннан тыңларга мөмкин. Түбәндәге тапшырулар сезгә ислам дине кыйммәтләрен җиткереп торачак:**

| | ТАПШЫРУ ИСЕМЕ | ЭФИРГА ЧЫГУ СӘГАТЕ |
|---|---|---|
| 1. | "Мөхәммәд Пәйгамбәр салләллаһу галәйһи вә сәлләмнең тормышы турында хикәятләр" | 03:30, 07:30, 12:30, 17:30, 23:30 |
| 2. | «Мәүлид» | 01:00, 06:00, 11:00, 15:00, 21:00 |
| 3. | «Пәйгамбәр медицинасы» | 00:00 һәм 12:00 |
| 4. | «Әбү Хәнифә" | 02:30, 09:30, 19:30 |

## Сезне Өркештә көтәләр

**1-15 АВГУСТ** көннәрендә Кукмара районының Өркеш авылында мөслимәләр өчен лагерь эшләячәк. Ислам нигезләре, йога, медицина буенча дәресләр, гүзәл табигать, саф һава, яңа дуслар, Зур Сабантуй – вакытыңны күңелле һәм файдалы уздырыйм дисәң, тагы ни кирәк? Коръән укырга өйрәнергә, ислам буенча гыйлемнәрен тирәнәйтергә теләгән кызларны – югары уку йорты студентларын һәм 9-11 нче сыйныф укучыларын Фәния абыстай Җәләлиева Өркеш лагеренда көтә.



*Автобус Казанның Гадел мәчетеннән ("Кояшлы шәһәр") 1 августта 8.30 да кузгала. Тел.:89093097135; 88436430583.*



реклама

## ШКОЛА УСМАНИЯ

**объявляет набор учащихся на новый 2015-2016 учебный год**

Питание халяль продуктами, факультативные занятия по религиозным предметам, раздельные занятия по физкультуре. Расписание с учетом времени намазов.

**г. Казань, ул. Мусы Бигиева, 38,**
**Телефон: 8 (843) 511-93-64, 8 9655 88 18 59**


## БОЛГАР ИСЛАМ БЕЛЕМ БИРҮ ҮЗӘГЕ ӨЧЕН ЭСКИЗ ЭШЛӘНМӘЛӘР КОНКУРСЫ УЗДЫРЫЛА

Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинның боерыгы буенча Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте Болгар ислам белем бирү үзәге өчен эскиз эшләнмәләр конкурсын игълан итә. Конкурс иң яхшы архитектура идеяләрен ачыклау, тарихи җирлек үзенчәлекләрен һәм хәзерге төзелеш материалларын, конструкцияләрен уңышлы файдалану һәм төзелешне планлаштыру максатыннан уздырыла.

***Конкурс таләпләре белән dumrt.ru сайтындагы нигезләмәдән танышырга мөмкин***


**ДИН вә Мәгыйшәт**

*Июль саны, №7 (240)*

**Мөхәррир:** Нәүбәһар КӘБИРОВА
**Дизайнер:** Гүзәл МИҢНУЛЛИНА

**РЕДАКЦИЯНЕҢ һӘМ НӘШЕР ИТҮЧЕНЕҢ АДРЕСЫ:**
*420111, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в*
**Электрон адрес:** *naubahar67@list.ru*
**Телефон:** *+7 950 326 38 36*

**РЕДАКЦИЯ СОВЕТЫ:**
*Татарстан мөфтие, Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте рәисе* ***Камил СӘМИГУЛЛИН***
*«Хузур» нәшрият йорты директоры* ***Ришат ХӘМИДУЛЛИН***
*ҖМДНнең дәгъвәт бүлеге җитәкчесе* ***Нияз САБИРОВ****;*
*Татарстанның баш казые* ***Җәлил ФАЗЛЫЕВ****;*
*Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең Голәмалар шурасы әгъзасы* ***Габдулла ӘДҺӘМОВ***

**ЯЗЫЛУ ИНДЕКСЫ: 16046**
**Татарстанның һәр почта бүлегендә язылырга мөмкин**

**Гамәлгә куючы:** *Үзәкләшкән дини оешма - Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәте (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 6/27).*
**Нәшир:** *«Хузур» нәшрият йорты (420111, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Лобачевский урамы, 10в)*

*Газета Татарстан Республикасы матбугат һәм мәгълүмат министрлыгында 1993 нче елның 16 нчы февралендә 240 нчы номер белән теркәлгән.*
Материалларны күчереп бастырганда кайдан алынганлыгын, авторларын күрсәтү мәҗбүри.
Газета **'Татмедиа» АҖ филиалы - «Идел-Пресс»** полиграфия-нәшрият комплексында басылды *(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2).*
**Тираж: 5 мең данә** Заказ **№ 9057**
Газетаны ваклап сатуда тәкъдим ителгән бәя - **6 сум.**
График буенча бу санга **15 нче июль** көнне **20.00 сәгатьтә** кул куелырга тиеш иде.
Кул куелды: **20.00 сәгатьтә.**